Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи

# иң кирәкле

# ДОГАЛАР

Түбән Кама 2011

ББК 86.38
© Ниязетдин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи
e-mail: mullaniyaz@mai.ru

*Китапның асылы «Хисънул-Муслим»нән алынды*

بسم الله الرحمن الرحيم

# Зикернең фазыйләте

Аллаһ әйтте:

**«Мине итагатьлек белән зикер итегез! Мин сезне савап вә мәгъфират белән искә алырмын. Миңа шөкер итегез һәм көферлек кылмагыз»[1]**

Янә Аллаһ әйтте:

**«Әй иман китерүчеләр! Аллаһны күп зикер итегез!»[2]**

Янә Аллаһ әйтте:

**«Аллаһны күп зикер кылучы ирләр һәм хатыннар, Аллаһ аларга мәгъфирәт һәм олуг әҗер-саваплар хәзерләде»[3]**

Янә Аллаһ әйтте:

**«Раббыңны көннең әүвәлендә һәм ахырында түбәнчелек вә курку илә эчеңнән генә кычкырмыйча зикер ит, һәм дә гафилләрдән булма»[4]**

Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

***– «Раббысын зикер итүче һәм Аны зикер итмәүчеләрнең мисалы — тере һәм үле кебек»[5]***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***– «Сезгә, Раббыгыз каршында иң пакьрәге булган, дәрәҗәләрегезне иң югарыга күтәргән, сезнең өчен алтын вә көмеш сарыф итүдән дә хәерлерәк булган, һәм башларыгызны чабучы вә сез аларның башларын чаба торган дошманнарыгыз белән очрашудан да яхшырак булган, иң хәерле гамәлегезне әйтимме?», — диде. Алар: «Әлбәттә!», — диделәр. Пәйгамбәр ﷺ: «Аллаһ тәгаләне зикер итү», — диде.***

1 әл-Бәкара 152
2 әл-Әхзәб 41
3 әл-Әхзәб 35
4 әл-Әгъраф 205
5 Бохари 6407

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***– «Аллаһ тәгалә әйтә: «Колым Мине нинди дип саный, Мин шундый булырмын[6], һәм ул Мине зикер иткәндә, Мин аның белән бергә булам[7]. Әгәр ул Мине яшерен зикер итсә, Мин дә аны яшерен зикер итәрмен; әгәр ул Мине башка кешеләр янында зикер итсә, Мин аны алардан да хәерлерәкләр (ягъни, фәрештәләр) янында зикер итәрмен; әгәр ул Миңа бер карышка якынайса, Мин аңа бер терсәккә якынаермын; әгәр ул Миңа бер терсәккә якынайса, Мин аңа бер сажинга[8] якынаермын; әгәр ул Миңа атлап килсә, Мин аңа йөгереп килермен», — диде»[9]***

Габдуллаһ бин Бусрдан ؓ риваять ителә:

***– «Бер кеше пәйгамбәребезгә ﷺ: «Әй Аллаһның расүле! Дөреслектә, Исламның хөкемнәре минем өчен бик күбәйде, син миңа мин нык үти торган берәр нәрсә әйт», — диде. Пәйгамбәр ﷺ аңа: «Синең телең һәрдаим Аллаһны зикер итүдән туктамасын», — диде»***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***– «Кем Коръәннән бер хәреф укый икән, аңа шуның өчен бер яхшылык языла, ә һәрбер яхшылык өчен ун әҗер бирелә. Мин «ӘлифЛәәмМиим» — бер хәреф ул дип әйтмим, юк, «Әлиф» — хәреф, «Ләм» — хәреф һәм «Мим» — хәреф»[10]***

Гукъбә бин Гамир ؓ әйтте:

***– «Бервакыт без әс-Суффәдә[11] булганда, безнең яныбызга Аллаһның расүле ﷺ чыкты, һәм: «Кайсыгыз көндә иртә белән Бутхәнга[12] яки әл-Гакыйкка[13] барып***

---

6 Ягъни, кеше Аллаһтан нәрсә өмет итсә, Аллаһ аңа шуны эшләр

7 Ягъни, Аллаһ аңа бу вакытта ярдәмен итә

8 Сажин - озынлык үлчәү берәмлеге

9 Бохари 7405, Мөслим 2675

10 Тирмизи 2910

11 Пәйгамбәр ﷺ заманында аның мәчетендә фәкыйрь мөһәҗирләр өчен билгеләнгән мәхсус урын, шуңа да алар «әс-Суффә әһелләре» дип аталдылар

12 Мәдинә янында булган урынның исеме

13 Мәдинәдәге үзәнлекнең исеме

***бернинди гөнаһ кылмыйча һәм туганнары белән кардәшлекне өзмичә ике зур өркәчле дөяне алып кайтасы килә?», — дип сорады. Без: «Әй Аллаһның расүле! Без!», — дидек. Ул: «Сезнең берәрегезнең иртә белән мәчеткә барып Аллаһ ﷻ Коръәненнән ике аять өйрәнүе яки укуы ул ике дөядән хәерлерәк була. Өчне укуы өч дөядән, дүртне уку – дүрттән хәерлерәк, һәм шулай күпме укыганга карап дөя саннары да була», — диде»[14]***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***– «Кем дә кем Аллаһны зикер итмичә (искә алмыйча) кая гына булса да утыра икән, аңа Аллаһның тирасы[15] булыр. Шулай ук, кем дә кем Аллаһны искә алмыйча кая гына булса да ята икән, аңа да Аллаһның тирасы булыр»[16]***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***«Әгәр дә кешеләр Аллаһ тәгаләне зикер итмәгән һәм пәйгамбәрләренә салават әйтмәгән мәҗлестә (җыенда) булсалар, аларга һичшиксез тира (хәсрәт) ирешер. Әгәр Аллаһ теләсә аларны җәза кылыр, теләсә гафу итәр»[17]***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***«Әгәр дә кешеләр бер урында утырганнан соң Аллаһ тәгаләне зикер итмичә (искә алмыйча) торып китәләр икән, ул кешеләр сасыган ишәк үләксәсе янынннан торып киткән кебек китәрләр һәм аларга хәсрәт булыр»[18]***

Янә пәйгамбәр ﷺ әйтте:

***«Хакыйкатьтә, Раббыгыз тәбәракә вә тәгалә оялчан һәм юмарт. Колы Аңа кулларын күтәреп дога кылса, аның кулларын буш кайтарудан, аннан ояла»[19]***

14 Мөслим 803
15 Ягъни, ул кешегә Аллаһтан хәсрәт булыр
16 Әбү Дауыд 4856
17 Тирмизи 3380
18 Әбү Дауыд 4855
19 Әбү Дауыд 1488

# Дога кылуның әдәпләре

Аллаһка дога кылганда кабул булсын өчен түбәндәгеләрне эшләү мөһим:

1 – Ихласлык;

2 – Доганы Аллаһка хәмед-сәнә вә пәйгамбәргә салават белән башлау, тәмамлаганда да шулай ук бетерү.

3 – Җитдилек белән сорау, доганың кабуллыгына инану һәм ашыктырмау.

4 – Күңел вә йөрәк белән бирелү.

5 – Шатлыкта да кайгыда да дога белән ялвару.

6 – Догада Аллһтан башкага ялвармау.

7 – Үзеңне, гаиләңне, балаларыңны һәм байлыгыңны, берсен дә ләгънәт кылмау.

8 – Аллаһка ялварганда бик кычкырып та, бик эчтән дә дога кылмау, ә уртача ялвару.

9 – Барча гөнаһларны тану һәм алар өчен гафу сорау, шулай ук Аллаһның рәхмәтен танып Аңа шөкер кылу.

10 – Доганың сүзләрен ясалма рәвештә рифмага салмау. Сораганда хәерлене генә сорау.

11 – Дога кылганда тыйнаклык, буйсынучанлык, өмет һәм курку белдерү.

12 – Хаксыз алынган нәрсә булса, аны хуҗасына кайтару һәм тәүбә итү.

13 – Доганы 3 тапкыр кабатлап әйтү.

14 – Кыйблага таба юнәлү.

15 – Дога кылганда кулларны күтәрү.

16 – Таһәратле булу.

17 – Дога кылучы изгелеккә өндәүче вә бозыклыктан тыючылардан булу.

18 – Башка кеше өчен дога кылганда, иң әүвәле үзең өчен сорау.

19 – Аллаһның күркәм исемнәрен вә камил сыйфатларын әйтеп сорау.

20 – Гөнаһлардан саклану һәм сораучының ризыгы да, киеме дә хәләл юл белән кәсеп ителгән булу.

21 – Гөнаһка вә туганлык җепләрен өзүгә китерә торганны сорамау.

## Дога кабул була торган вакытлар һәм урыннар

1 – Кадер кичендә.

2 – Төннең өченче өлешендә.

3 – Азан белән камәт арасында.

4 – Яңгыр яуганда.

5 – Җиһәдтә һөҗүм вакытында.

6 – Җомга көненең бер өлешендә.

7 – Зәмзәм суы эчкәндә.

8 – Сәҗдә вакытында.

9 – Фарыз намазларыннан соң.

10 – Тәшәһһүд ахырында.

11 – Мөселман кардәшең гаеп (янында булмаган) вакытта аның өчен дога кылу.

12 – Гарәфәт көнендә (хаҗда булучыга).

13 – Рамазан аенда.

14 – Золым кылынган вә җәберләнгән кешенең догасы.

15 – Ата-ананың баласына карата догасы.

16 – Мөсафир кешенең догасы.

17 – Ураза тотучының догасы.

18 – Авыз ачканда.

19 – Гадел имамның догасы.

20 – Изге баланың догасы.

21 – Хаҗда беренче ике баганага таш аткач.

22 – Кәгъбәтуллаһ эчендә, шулай ук хиҗер эчендә, чөнки ул Кәгъбәтуллаһның бер өлеше.

23 – Сафа һәм Марва калкулыкларында.

Гомүмән алганда, мөселман һәрвакытта да Аллаһка дога белән ялварырга тиеш, чөнки Аллаһ тәгалә әйтте: **«Әгәр колларым синнән Минем турында сорасалар, хакыйкатьтә, Мин якын. Дога кылучы Миңа дога белән мөрәҗәгать итсә, Мин мөрәҗәгатенә җавап бирәмен»**[20] Шулай да, искә алып узган вакытларга һәм урыннарга аерым әһәмият бирергә кирәк.

## 1 – Йокыдан уянгач та укыла торган зикер-догалар

١ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى أَحْيَانَا بَعْدَ مَا أَمَاتَنَا وَإِلَيْهِ النُّشُورُ»

***1 – /Әлхәмдү лилләһил-ләҙи әхйәнә бәгьдә мә әмәтәнә үә иләйһин-нүшүр/***

1 — «Безне үле кылганнан соң[21] терелткән Аллаһка барча мактаулар булсын, һәм Аңа кире терелеп Кыяматтә җыелу»[22].

٢ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَىْءٍ قَدِيرٌ سُبْحَانَ اللَّهِ وَالْحَمْدُ لِلَّهِ وَلاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَاللَّهُ أَكْبَرُ وَلاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلاَّ بِاللَّهِ الْعَلِيِّ الْعَظِيمِ، رَبِّ اغْفِرْ لِى»

***2 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмду үә һүә галә күлли шәй‘ин кадир, сүбхәнәллаһи үәлхәмдүлилләһи үә лә иләһә иллә Аллаһ, үә Аллаһү әкбәръ, үә лә хәүлә үә лә куәтә иллә билләһил-галийил-гаҙыйм, Раббигьфирли/***

2 — «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе

---

20 әл-Бәкара 186

21 Йокы, үлемнең кече кардәше

22 Бохари 6312

генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле. Аллаһ барча кимчелектән пакь вә Аңа барча мактау һәм Аллаһтан башка иләһ юк. Аллаһ бөек, һәм әл-Галий әл-Газыйм булган Аллаһтан башка көч-куәт юк. Раббым, мине ярлыка»[23].

٣ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى عَافَانِى فِى جَسَدِى وَرَدَّ عَلَىَّ رُوحِى وَأَذِنَ لِى بِذِكْرِهِ»

***3 – /Әлхәмдулилләһилләҙи гафәни фи җәсәди үә раддә галәййә рухи үә әҙинә ли биҙикриһи/***

3 — «Минем тәнемне савыктырган, җанымны кайтарган һәм миңа Аны зикер итәргә рөхсәт иткән Аллаһка барча мактаулар булсын»[24]

٤ – «إِنَّ فِي خَلْقِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ وَاخْتِلَافِ اللَّيْلِ وَالنَّهَارِ لَآيَاتٍ لِأُولِي الْأَلْبَابِ ... يَاأَيُّهَا الَّذِينَ آمَنُوا اصْبِرُوا وَصَابِرُوا وَرَابِطُوا وَاتَّقُوا اللَّهَ لَعَلَّكُمْ تُفْلِحُونَ»

***4 – //***

4 — «Дөреслектә, күкләрнең һәм җирнең халикъ кылынуында, янә төн белән көннең алышынуында саф акыл ияләре өчен (Аллаһ тәгаләнең барлыгына һәм берлегенә) аятьләр (галәмәтләр) бар...

Әй мөэминнәр! Тормыш авырлыкларына, дин мәшәкатьләренә, төрле казаларга һәм дошманнарның һөҗүмнәренә сабыр итегез! Нинди генә авырлыклар килсә дә, ул авырлыкларны бергәләп күтәрегез, чыдам-сабыр булыгыз, динегезне саклауда берләшеп, дошманга каршы бик таза торыгыз һәм Аллаһтан куркыгыз, шаять өстенлек табарсыз!»[25]

---

23 Ибен Мәҗәһ 3878. Кем төнлә уянганнан соң ошбу сүзләрне әйтсә – гөнаһлары ярлыканыр, дога кылса – догасы кабул булыр, торып таһәратләнеп намаз укыса – намазы кабул булыр

24 Тирмизи 3401

25 әли-Гыймран 190-200. Бохари 183, Мөслим 763. Пәйгамбәребез ﷺ төнлә уянгач та ошбу аятьләрне укый торган иде

## 2 – Кием кигәндә укыла торган дога

٥ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى كَسَانِى هَذَا الثَّوْبَ
وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّى وَلاَ قُوَّةٍ»

***5 – /Әлхәмдүлилләһил-ләҙи кәсәни һәҙәҫ-ҫәүбә үә разәканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ/***

5 — «Минем көч-куәтемнән тыш, мине ошбу киемгә киендергән вә аның белән мине ризыкландырган Аллаһка барча мактаулар булсын»[26]

## 3 – Яңа кием кигәндә укыла торган дога

٦ – «اللَّهُمَّ لَكَ الْحَمْدُ أَنْتَ كَسَوْتَنِيهِ، أَسْأَلُكَ خَيْرَهُ وَخَيْرَ
مَا صُنِعَ لَهُ، وَأَعوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهِ وَشَرِّ مَا صُنِعَ لَهُ»

***6 – /Аллаһүммә ләкәлхәмд! Әнтә кәсәүтәниһи әс‘әлүкә хайраһү үә хайрә мә сунига ләһү, үә әгүҙү бикә мин шәрриһи үә шәрри мә сунига ләһү/***

6 — «Әй Аллаһ, Сиңа барча мактау! Син мине киендердең. Синнән бу киемнең яхшылыгын вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең яхшылыгын сорыйм, һәм Сиңа аның явызлыгыннан вә аның нәрсә өчен эшләнгәненең явызлыгыннан сыенам»[27]

## 4 – Яңа кием киючегә укыла торган дога

٧ – «تُبْلِى وَيُخْلِفُ اللَّهُ تَعَالَى»

***7 – /Түбли үә йүхлифүллаһү тәгалә/***

7 — «Киem тузганнан соң, Аллаһ тәгалә сиңа аны яңа белән алыштыра»[28]

---

26 Әбү Дауыд 4023. Кем кием кигәндә ошбу доганы әйтсә, аның гөнаһлары ярлыканыр

27 Әбү Дауыд 4020, ибен Мәҗәһ 1767

28 Әбү Дауыд 4020

٨ – «الْبَسْ جَدِيدًا وَعِشْ حَمِيدًا وَمُتْ شَهِيدًا»

***8 – /Илбис җәдидән үә гыйш хәмидән үә мүт шәһидән/***

8 — «Яңа килеш ки, мактауга лаек булып яшә һәм шәһид булып үл»[29]

## 5 – Кием салгач әйтелә

٩ – «بسم الله»

***9 – /Бисмилләһ/***

9 — «Аллаһ исеме белән»[30]

## 6 – Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога

١٠ – «[ بسم الله ] اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْخُبُثِ وَالْخَبَائِثِ»

***10 – /Бисмилләһ! Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-хубҫи үәл-хабәиҫ/***

10 — «Аллаһ исеме белән! Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Сиңа ир һәм хатын-кыз җенесеннән булган җеннәрдән сыенам»[31]

## 7 – Бәдрәфтән чыккач укыла торган дога

١١ – «غُفْرَانَكَ»

***11 – /Гуфранәк/***

11 — «Гафу ит»[32]

## 8 – Таһәрат алдыннан әйтелә

١٢ – «بسم الله»

---

29 Ибен Мәҗәһ 3558

30 Сахих әл-Җәмигь вә әс-Сагыйр 3610. Кием салгач бу сүзне әйтү кешеләрнең гаурәтләре белән җеннәрнең күзләре арасында пәрдә булып тора

31 Бохари 142, Мөслим 375

32 Әбү Дауыд 30

***12 – /Бисмилләһ/***

12 — «Аллаһ исеме белән»[33]

## 9 – Таһәрат алганнан соң әйтелә торган зикер-дога

١٣ – «أَشْهَدُ أَنْ لا إِلَهَ إِلَّا اللهُ وَحْدَهُ لا شَرِيكَ
لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّداً عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ»

***13 – /Әшһәдү әллә иләһә илләАллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ/***

13 — «Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле»[34]

١٤ – «أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَشْهَدُ أَنَّ مُحَمَّدًا
عَبْدُهُ وَرَسُولُهُ اللَّهُمَّ اجْعَلْنِى مِنَ التَّوَّابِينَ وَاجْعَلْنِى مِنَ الْمُتَطَهِّرِينَ»

***14 – /Әшһәдү әллә иләһә илләАллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ. Аллаһүммәҗгални минәт-тәүүәбин үәҗгални минәл-мүтәтаһһирин/***

14 — «Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле. Әй Аллаһ! Мине күп тәүбә кылучылардан һәм пакьланучылардан кыл»[35]

١٥ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ
إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ أَسْتَغْفِرُكَ وَأَتُوبُ إِلَيْكَ»

***15 – /Сүбхәнәкә Аллаһүммә үә бихәмдик, әшһәду әллә***

33 Әбү Дауыд, ибен Мәҗәһ

34 Мөслим 234

35 Тирмизи 55. Кем таһәратне иң күркәм рәвештә, барча сөннәтләре белән алса һәм аннары ошбу сүзләрне әйтсә, аңа Җәннәтнең сигез ишеге ачылыр һәм ул теләгән ишегеннән керер

***иләһә иллә әнт, әстәгьфирукә үә әтүбү иләйк/***

15 — «Әй Аллаһ! Син барча кимчелекләрдән пакьсең һәм Сиңа барча мактау. Синнән башка иләһ юк дип шаһитлык кылам, Синнән ярлыкавыңны сорыйм һәм Сиңа тәүбә итәм»[36]

## 10 – Өйдән чыкканда укыла торган дога

١٦ – «بِسمِ اللهِ تَوَكَّلْتُ عَلَى اللهِ، وَلا حَولَ وَلا قُوَّةَ إلاَّ باللهِ»

***16 – /Бисмилләһ, тәүәккәлтү галәАллаһ, үә лә хәүлә үә лә куүәтә иллә билләһ/***

16 — «Аллаһ исеме белән. Мин Аллаһка тәвәккәл иттем һәм Аллаһтан башка көч тә, куәт тә юк»[37]

١٧ – «بِسْمِ اللهِ تَوَكَّلتُ عَلَى اللهِ، اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ أَنْ أَضِلَّ أَوْ أُضَلَّ، أَوْ أَزِلَّ أَوْ أُزَلَّ، أَوْ أَظْلِمَ أَوْ أُظْلَمَ، أَوْ أَجْهَلَ أَوْ يُجْهَلَ عَلَيَّ»

***17 – /Бисмилләһ, тәүәккәлтү галәАллаһ, Аллаһүммә инни әгүҙү бикәән әдыйллә әү үдаллә, әү әзиллә әү үзәллә, әү аҙълимә әү уҙъләмә, әү әҗһәлә әү йүҗһәлә галәййә/***

17 — «Аллаһ исеме белән. Мин Аллаһка тәвәккәл иттем. Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин адашуымнан яки адаштырылуымнан, хаталануымнан яки хаталандырылуымнан, үзем золым кылудан яки миңа золым кылуларыннан, мин башкаларга зыян вә зарар китерә торган җәһилләр гамәленнән яки башкаларның миңа зыян вә зарар китерә торган җәһилләр гамәленнән Сиңа сыенам»[38]

---

36 әт-Тәргиб вә әт-Тәрһиб 350

37 Әбү Дауыд 5095. Кеше өеннән чыкканда ошбу доганы укыса, аңа: «Син туры юлдан баручы, тынычсызлык китерә торган нәрсәләрдән котылучы һәм барча явызлыклардан сакланучысың», – дип әйтелер, һәм шәйтан аннан ераклашыр

38 Әбү Дауыд 5094

## 11 – Өйгә кергәндә укыла торган дога

١٨ – «بِسْمِ اللَّهِ وَلَجْنَا وَبِسْمِ اللَّهِ خَرَجْنَا وَعَلَى اللَّهِ رَبِّنَا تَوَكَّلْنَا» ثُمَّ لْيُسَلِّمْ عَلَى أَهْلِهِ

***18 – /Бисмилләһи үәләҗнә үә бисмилләһи харәҗнә үә галәАллаһи раббинә тәүәккәлнә/***

18 — «Аллаһ исеме белән кердек вә Аллаһ исеме белән чыктык һәм Раббыбыз Аллаһка тәвәккәлләдек»

Бу сүзләрне әйткәннән соң, керүче йорт әһелләренә сәлам бирергә тиеш[39].

## 12 – Мәчеткә барганда укыла торган дога

١٩ – «اللَّهُمَّ اجْعَلْ فِي قَلْبِي نُورًا، وَفِي بَصَرِي نُورًا، وَفِي سَمْعِي نُورًا، وَعَنْ يَمِينِي نُورًا، وَعَنْ يَسَارِي نُورًا، وَفَوْقِي نُورًا، وَتَحْتِي نُورًا، وَأَمَامِي نُورًا، وَخَلْفِي نُورًا، وَاجْعَلْ لِي نُورًا»

***19 – /Аллаһүммәҗгал фи калби нүран, үә фи бәсари нүран, үә фи сәмги нүран, үә ган йәмини нүран, үә ган йәсәри нүран, үә фәүкый нүран, үә тәхти нүран, үә әмәми нүран, үә халфи нүран, үәҗгал-ли нүран/***

19 — «Әй Аллаһ! Йөрәгемдә, күрүемдә, ишетүемдә, уң ягымда, сул ягымда, өстемдә, астымда, алдымда вә артымда нур кыл, һәм миңа нур бир»[40]

## 13 – Мәчеткә кергәндә укыла торган дога

٢٠ – «بِسْمِ اللَّهِ وَالسَّلاَمُ عَلَى رَسُولِ اللَّهِ اللَّهُمَّ

39 Әбү Дауыд 5096. Мөслимдә (2018) килгән риваятьтә болай диелде: «Әгәр кеше өенә кергәндә һәм ашаганда Аллаһ тәгаләне зикер итсә (ягъни, Бисмилләһ дип әйтсә), шәйтан үзенең иярченнәренә: «Сезгә монда торырга урын да, ашарга ризык та юк!», — дип әйтер. Әгәр ул кеше өенә кергәндә Аллаһ тәгаләне зикер итмичә керсә, шәйтан иярченнәренә: «Сез торырга урын таптыгыз», — дип әйтер. Әгәр ул ашаганда да Аллаһ тәгаләне зикер итмәсә, шәйтан үзенең иярченнәренә: «Сез торырга урын да, ашарга ризык та таптыгыз!», — дияр

40 Бохари 6316. Шулай ук бу хәдис башка өстәмәләр белән башка хәдисләр җыентыгында да бар

اغْفِرْ لِى ذُنُوبِى وَافْتَحْ لِى أَبْوَابَ رَحْمَتِكَ»

***20 – /Бисмилләһ, үәссәләму галә расүлилләһ, Аллаһүммәгьфир ли ҙүнүби үәфтәх ли әбүәбә рахмәтик/***

20 — «Аллаһ исеме белән, Аллаһның расүленә сәлам. Әй Аллаһ! Минем гөнаһларымны ярлыка һәм миңа Үзеңнең рәхмәт ишекләреңне ач»[41]

## 14 – Мәчеттән чыкканда укыла торган дога

٢١ – «بِسْمِ اللَّهِ وَالسَّلاَمُ عَلَى رَسُولِ اللَّهِ اللَّهُمَّ
اغْفِرْ لِى ذُنُوبِى وَافْتَحْ لِى أَبْوَابَ فَضْلِكَ»

***21 – /Бисмилләһ, үәссәләму галә расүлилләһ, Аллаһүммәгьфир ли ҙүнүби үәфтәх ли әбүәбә фәдълик/***

21 — «Аллаһ исеме белән, Аллаһның расүленә сәлам. Әй Аллаһ! Минем гөнаһларымны ярлыка һәм миңа Үзеңнең фазыйләт ишекләреңне ач»[42]

## 15 – Азан әйткәндә укыла торган зикер-догалар

22 — Азанны мөәзин артыннан кабатлап бара, һәм ул:

«حَيَّ عَلَى الصَّلاَةِ وَحَيَّ عَلَى الْفَلاَحِ»

***/Хәййә галәс-саләһ. Хәййә галәс-саләһ. Хәййә галәл-фәләх. Хәййә галәл-фәләх/***

дигәннән соң, кабатлап баручы һәрбер җөмләдән соң:

«لاَ حَوْلَ وَلاَ قُوَّةَ إِلَّا بِاللَّهِ»

***/Лә хәүлә үә лә куүәтә илләә билләһ/*** — дип әйтә.

23 — Мөәзин азанда шәһәдәт кәлимәләрен әйткәннән соң, тыңлаучы:

---

41 Ибен Мәҗәһ 771
42 Ибен Мәҗәһ 771

«أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ وَأَنَّ مُحَمَّدًا عَبْدُهُ
وَرَسُولُهُ رَضِيتُ بِاللَّهِ رَبًّا وَبِمُحَمَّدٍ رَسُولاً وَبِالإِسْلاَمِ دِينًا»

***/Әшһәдү әллә иләһә илләАллаһ, үәхдәһү лә шәрикә ләһү үә әшһәдү әннә Мүхәммәдән габдүһү үә расүлүһ, радыйтү билләһи раббә, үә би-Мүхәммәдин расүлә, үә бил-исләми динә/***

«Шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Аллаһтан башка иләһ юк, һәм шаһитлык кылам — хакыйкатьтә, Мөхәммәд Аның колы вә расүле. Мин Аллаһтан Раббы буларак, Мөхәммәдтән расүл буларак һәм Исламнан дин буларак разыймын»

24 — Мөәзин артыннан кабатлап бетергәч пәйгамбәребезгә салават әйтә (21нче биттә 35нче дога).

٢٥ – «اللَّهُمَّ رَبَّ هَذِهِ الدَّعْوَةِ التَّامَّةِ وَالصَّلاَةِ الْقَائِمَةِ آتِ مُحَمَّدًا الْوَسِيلَةَ
وَالْفَضِيلَةَ وَابْعَثْهُ مَقَامًا مَحْمُودًا الَّذِى وَعَدْتَهُ [ إِنَّكَ لَا تُخْلِفُ الْمِيعَاد ]»

***25 – /Аллаһүммә раббә һәҙиһид-дәгьуәтит-тәммәһ, үәс-саләтил-ка‘имәһ, әти Мүхәммәдәнил-үәсиләтә үәл-фәдыйләһ, үәбгаҫһү мәкамәм-мәхмүдәнилләҙи үәгадтәһ, иннәкә лә тухлифүл-мигад/***

25 — «Әй, бу мөкәммәл чакыруның һәм торгызыласы намазның Раббысы булган Аллаһ! Мөхәммәдкә бөек вә югары дәрәҗә бир һәм аны Үзең вәгъдә иткән мактаулы урынга җибәр! Хакыйкатьтә, Син вәгъдәңне бозмыйсың!»[43]

26 — Азан белән камәт арасында дога кабул була, шуның өчен кеше бу вакытта үзе өчен дога кылу тиеш.

## 16 – Истихара (хәерлене сорау) намазының догасы

Җәбир бин Габдуллаһ радыяллаһү ганһүмә әйтте:

— «Аллаһның расүле безгә барча эшләребездә дә

43 Бохари 614. Кем азаннан соң ошбу доганы укыса, аңа Кыямәт көнендә пәйгамбәребезнең шәфәгате ирешер

истихара кылуны (хәерлесен сорауны) Коръән сүрәсен өйрәткән кебек өйрәтә иде, һәм әйтә иде: «Әгәр дә берәрегез нинди дә булса эш эшләргә уйласа, фарыз намазыннан башка ике ракәгать нәфел намазы укып ошбу доганы әйтсен:

٢٧ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْتَخِيرُكَ بِعِلْمِكَ وَأَسْتَقْدِرُكَ بِقُدْرَتِكَ، وَأَسْأَلُكَ مِنْ فَضْلِكَ الْعَظِيمِ، فَإِنَّكَ تَقْدِرُ وَلاَ أَقْدِرُ وَتَعْلَمُ وَلاَ أَعْلَمُ وَأَنْتَ عَلاَّمُ الْغُيُوبِ، اللَّهُمَّ إِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ خَيْرٌ لِى فِى دِينِى وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى - أَوْ قَالَ عَاجِلِ أَمْرِى وَآجِلِهِ - فَاقْدُرْهُ لِى وَيَسِّرْهُ لِى ثُمَّ بَارِكْ لِى فِيهِ، وَإِنْ كُنْتَ تَعْلَمُ أَنَّ هَذَا الأَمْرَ شَرٌّ لِى فِى دِينِى وَمَعَاشِى وَعَاقِبَةِ أَمْرِى - أَوْ قَالَ فِى عَاجِلِ أَمْرِى وَآجِلِهِ - فَاصْرِفْهُ عَنِّى وَاصْرِفْنِى عَنْهُ، وَاقْدُرْ لِى الْخَيْرَ حَيْثُ كَانَ ثُمَّ أَرْضِنِى بِهِ»

***27 – /Аллаһүммә инни әстәхирукә бигыйлмик, үә әстәкъдирукә бикудратик, үә әс‘әлүкә мин фадъликәл-газыйм, фә‘иннәкә тәкъдирү үә лә әкъдир, үә тәгьләмү үә лә әгьләм, үә әнтә галләмүл-гуйүб. Аллаһүммә ин күнтә тәгьләмү әннә һәзәл-әмра хайрун ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри фәкъдүрһү ли үә йәссирһү ли сүммә бәрик ли фиһ, үә ин күнтә тәгьләм әннә һәзәл-әмра шәррун ли фи дини үә мәгаши үә гакыйбәти әмри фәсрыйфһү ганни үәсрыйфни ганһү үәкъдүр лиәл-хайра хәйсү кәнә сүммә әрдыйни биһ/***

27 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Синең гыйлемең белән Синнән хәерлесен сорыйм, Синең кодрәтең илә Синнән көч сорыйм, Синең бөек фазылыңнан сорыйм! Дөреслектә, Синең көчең җитә ә минем көчем җитми, Син беләсең ә мин белмим, һәм Син барча яшеренне белүчесең! Әй Аллаһ! Әгәр Син бу эшнең (нәрсә икәнен әйтеп китә) миңа динемдә дә, тормышымда да һәм эшләремнең ахыргы нәтиҗәсендә дә[44] (бу һәм киләсе дөньяда) хәерле икәнлеген белсәң, аны миңа тәкъдир кыл, аны миңа җиңеләйт һәм миңа анда бәрәкәт бир. Әгәр Син бу эшнең миңа динемдә дә, тормышымда да

44 Ягъни, ахирәттә

һәм эшләремнең ахыргы нәтиҗәсендә дә (бу һәм киләсе дөньяда) зыянлы вә яман икәнлеген белсәң, аны минән читләштер вә мине аннан читләштер һәм ул эш кайда гына булса да миңа хәерлесен тәкъдир кыл, соңра мине аннан канәгать кыл»[45]

Аллаһка истихара кылып хәерлесен сораган һәм мөэминнәр белән киңәшләшеп эшендә сабит булган кеше беркайчан да үкенмәс. Аллаһ тәгалә әйтте: **«Эшеңдә алар белән киңәшләш, ә инде аны эшләргә карар кылсаң, Аллаһка тәвәккәллә»** (әли-Гыймран 159)

## 17 – Иртә һәм кич укыла торган догалар

٢٨ – «اللَّهُ لَا إِلَهَ إِلَّا هُوَ الْحَيُّ الْقَيُّومُ لَا تَأْخُذُهُ سِنَةٌ وَلَا نَوْمٌ لَهُ مَا فِي السَّمَاوَاتِ وَمَا فِي الْأَرْضِ مَنْ ذَا الَّذِي يَشْفَعُ عِنْدَهُ إِلَّا بِإِذْنِهِ يَعْلَمُ مَا بَيْنَ أَيْدِيهِمْ وَمَا خَلْفَهُمْ وَلَا يُحِيطُونَ بِشَيْءٍ مِنْ عِلْمِهِ إِلَّا بِمَا شَاءَ وَسِعَ كُرْسِيُّهُ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضَ وَلَا يَئُودُهُ حِفْظُهُمَا وَهُوَ الْعَلِيُّ الْعَظِيمُ»

***28 – /Аллаһү лә иләһә иллә һүәл-хәййүл-каййүм, лә тә‘хуҙүһү синәтү-үә лә нәүүм, ләһү мә фис-сәмәүәти үә мә фил-әръд, мәң-ҙәлләҙи йәшфәгү гыйңдәһү иллә би‘иҙниһ, йәгьләму мә бәйнә әйдиһим үә мә халфәһүм, үә лә йүхитунә бишәй‘им-мин гыйлмиһи иллә бимә шәә‘, үәсига күрсийүһүс-сәмәүәти үәл-әръд, үә лә йә‘үдүһү хифҙуһүмә үә һүәл-галийүл-гаҙыйм/***

28 — «Аллаһ – Аннан башка гыйбадәткә лаеклы зат юк. Ул – мәңге Тере, Ул – яшәешне Барлап торучы. Ул беркайчан йокымсырап черем итмәс. Ул беркайчан йокыга китмәс. Күкләрдә һәм җирдә булган һәрнәрсә Аныкы. Кем Аның каршысында, Аның рөхсәтеннән башка шәфәгать кыла алыр икән? Ул һәрнәрсәнең үткәнен дә, киләчәген дә белә. Тик алар гына, Аның гыйлеменнән, Ул Үзе теләп аларга белгерткән нәрсәдән башканы белмиләр, чолгап ала алмыйлар. Аның көрсие күкләрне һәм җирне үз эченә ала. Аларны саклау Аның

45 Бохари 1162

өчен бер дә авырлык китерми. Ул – барнәрсәдән дә Биек һәм Бөек»[46]

29 — Иртән һәм кич өчәр тапкыр ошбу сүрәләрне укучы барча начарлыклардан сакланыр: әл-Ихлас сүрәсе; әл-Фәләкъ сүрәсе һәм ән-Нәс сүрәсе.

٣٠ – «اللَّهُمَّ أَنْتَ رَبِّى، لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ، خَلَقْتَنِى وَأَنَا عَبْدُكَ، وَأَنَا عَلَى عَهْدِكَ وَوَعْدِكَ مَا اسْتَطَعْتُ، أَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّ مَا صَنَعْتُ، أَبُوءُ لَكَ بِنِعْمَتِكَ عَلَىَّ وَأَبُوءُ بِذَنْبِى، فَاغْفِرْ لِى، فَإِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ»

***30 – /Аллаһүммә әнтә рабби, лә иләһә иллә әнтә, халәкътәни үә әнә габдүкә, үә әнә галә гаһдикә үә үәгдикә мәстәтагтү, әгүҙү бикә мин шәрри мә санәгатү, әбү‘ү ләкә бинигьмәтикә галәййә үә әбү‘ү биҙәнби, фәгьфирли, фә‘иннәһү лә йәгьфирүҙҙүнүбә иллә әнт/***

30 — «Әй Аллаһ! Син минем Раббым. Синнән башка иләһ юк. Син мине халикъ кылдың, ә мин Синең колың һәм мин Синең гаһедеңә вә вәгъдәңә булдыра алганымча тугрылык саклаячакмын. Кылганнарымның явызлыгыннан Сиңа сыенам, Синең миңа биргән нигъмәтеңне таныйм һәм үземнең гөнаһымны таныйм. Минем гөнаһларымны ярлыка, хакыйкатьтә, Синнән башка гөнаһларны ярлыкаучы юк»[47]

٣١ – «بِسْمِ اللَّهِ الَّذِى لاَ يَضُرُّ مَعَ اسْمِهِ شَىْءٌ فِى الأَرْضِ وَلاَ فِى السَّمَاءِ وَهُوَ السَّمِيعُ الْعَلِيمُ»

***31 – /Бисмилләһилләҙи лә йәдурру мәгәсмиһи шәй‘үн фил-әръдый үә лә фис-сәмә‘, үә һүәс-сәмигуль-галим/*** өч тапкыр әйтелә

31 — «Аллаһ исеме белән. Аның исеме белән җирдә дә һәм күктә дә һичнәрсә зыян китерә алмый, һәм Ул —

46 әл-Бәкара 255. Кем дә кем бу аятьне иртән укыса, кичкә кадәр шәйтаннан сакланыр, ә кем кич белән укыса - иртәнгә кадәр шәйтаннан сакланыр

47 Бохари 6306. Кем бу сүзләргә инанып иртәнге якта әйтсә һәм кичкә кадәр үлеп китсә, ул Җәннәт әһеленнән була. Ә кем бу сүзләргә инанып кичке якта әйтсә һәм иртәнгә кадәр үлеп китсә, шулай ук Җәннәт әһеленнән була

Ишетүче, Белүче»[48]

٣٢ – «سُبْحَانَ اللَّهِ وَبِحَمْدِهِ»

***32 – /Сүбхәнәллаһи үә бихәмдиһ/***

32 — «Аллаһ һәр кимчелектән пакь һәм Аңа барча мактау»[49]

٣٣ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ، وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ، لَهُ الْمُلْكُ
وَلَهُ الْحَمْدُ، وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

***33 – /Лә иләһә илләә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмду үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/*** көндә иртә белән йөз тапкыр әйтелә

33 — «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк. Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау һәм Ул бар нәрсәгә кодрәтле»[50]

٣٤ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ»

***34 – /Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин шәрри мә халәкъ/*** көндә кич белән өч тапкыр әйтелә

34 — «Аллаһ ﷻ халикъ кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан, Аның камил сүзләренә[51] сыенам»[52]

48 Әбү Дауыд 5088. Кем бу сүзләрне иртән һәм кичтән өчәр тапкыр әйтсә, аңа һичнәрсә дә зыян итә алмый

49 Мөслим 2692. Кем дә кем бу сүзләрне иртән һәм кичен йөзәр тапкыр әйтә икән, Кыямәт көнендә ул кешедән дә яхшырак нәрсә белән килүче булмас, илләмәгәр шулай ук әйтүче яки аннан да арттырып әйтүче генә

50 Бохари 3293. Кем бу сүзләрне көненә йөз тапкыр әйтсә, ул 10 кол азат иткәнгә тиң була, янә аңа 100 изгелек языла һәм 100 явызлыгы җуела, янә бу сүзләр аңа көне буена кичкә кадәр шәйтаннан саклану чарасы була, һәм беркем дә моннан яхшыракны эшли алмый, илләә-мәгәр аннан арттырып кына әйтсә

51 Кәүния һәм шәрьгыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин, аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу, бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу, бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

52 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 6427. Кем бу сүзләрне кич белән 3 тапкыр әйтсә, ул төндә аңа бер хәшәрәтнең дә агуы зыян итмәс

٣٥ – «اللَّهُمَّ صَلِّ وَسَلِّمْ عَلَى نَبِيِّنا مُحَمَّدٍ»

***35 – /Аллаһүммә салли үә сәллим галә нәбийинә Мүхәммәд/*** көндә иртә һәм кич белән ун тапкыр әйтелә

35 — «Әй Аллаһ! Пәйгамбәребез Мөхәммәдкә салават вә сәлам кыл»[53]

## 18 – Йоклар алдыннан укыла торган догалар

36 — Йокларга ятыр алдыннан кулларны бер учка җыеп аларга бераз төкреп өрергә һәм түбәндәге сүрәләрне укырга:

— әл-Ихлас —

— әл-Фәләкъ —

— ән-Нәс —

Шуннан соң, баштан, йөздән һәм тәннең алгы ягыннан башлап ике уч белән бөтен тәнне сыпыра. Шушы тәртип буенча башта кулны учлап өреп, аннары сүрәләрне укып бөтен тәнне сыпыруны 3 тапкыр эшләргә[54]

٣٧ – «آية الكرسي»

***37 – //***

37 — Кем дә кем йоклар алдыннан «Аятел Көрси»не укый икән, Аллаһ аны иртәнгә кадәр барча явызлыктан саклый һәм аңа шәйтан якынлаша алмый[55]. (Тәрҗемәсе 28нче догада)

٣٨ – «اللَّهُمَّ أَسْلَمتُ نَفْسي إِلَيْكَ، وَوَجَّهتُ وَجْهي إِلَيْكَ، وَفَوَّضتُ أَمْري إِلَيْكَ، وَأَلجأْتُ ظَهري إِلَيْكَ رَغبَةً وَرَهبَةً إِلَيْكَ، لا مَلْجَأَ وَلاَ مَنْجا مِنْكَ إِلاَّ إِلَيْكَ، آمنْتُ بِكِتابِكَ الَّذي أَنْزَلْتَ؛ وَنَبِيِّكَ الَّذي أَرْسَلْتَ»

***38 – /Аллаһүммә әсләмтү нәфси иләйк, үә үәҗҗәһтү үәҗһи иләйк, үә фәүүәдътү әмри иләйк, үә әлҗә‘тү***

53 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 6357. Кем бу сүзләрне иртән һәм кич уны-шар тапкыр әйтсә, аңа Кыямәт көнендә пәйгамбәребезнең шәфәгате булыр

54 Бохари 5017

55 Бохари 2311

***ҙаһри иләйк, рагбәтән үә раһбәтән иләйк, лә мәлҗә‘ә үә лә мәнҗә минкә иллә иләйк, әмәнтү би китәбикәлләҙи әнзәлтә үә би нәбийикәлләҙи әръсәлтә/***

38 — «Әй Аллаһ! Мин нәфсемне Сиңа буйсындырдым, йөземне Сиңа юнәлдердем һәм эшләремне-хәлемне Сиңа тапшырдым. Синнән әҗер өмет итеп һәм газабыңнан куркып Сиңа сыендым. Синнән качу һәм котылу юк, иллә-мәгәр Сиңа гына! Мин Синең иңдергән Китабыңа һәм Син җибәргән пәйгамбәреңә иман китердем»[56]

## 19 – Төнлә йоклый алмыйча боргаланып ятканда укыла торган дога

٣٩ – «لَا إِلَهَ إِلَّا اللَّهُ الْوَاحِدِ الْقَهَّارُ رَبُّ السَّمَوَاتِ وَ الأَرْضِ وَ مَا بَيْنَهُمَا الْعَزِيزُ الْغَفَّارُ»

***39 – /Лә иләһә илләАллаһүл-үәхидил-каһһәр, раббүс-сәмәүәти үәл-әръдый үә мә бәйнәһүмәл-газизүл-гаффәр/***

39 — «әл-Вәхид әл-Каһһәр булучы Аллаһтан башка иләһ юк. Ул – әл-Газиз әл-Гаффәр, күкләрнең вә җирнең һәм алар арасындагы барча нәрсәнең Раббысы»[57]

## 20 – Йоклаганда төшендә куркучы һәм борчылучы укый торган дога

٤٠ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ غَضَبِهِ وَعِقَابِهِ وَشَرِّ عِبَادِهِ وَمِنْ هَمَزَاتِ الشَّيَاطِينِ وَأَنْ يَحْضُرُونِ»

***40 – /Әгүҙү би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин гадабиһи үә гыйкабиһи үә шәрри гыйбәдиһи үә мин һәмәзәтиш-шәйәтыйни үә эн йәхдурун/***

---

56 Бохари 7488, Мөслим 2710. Бу дога хакында пәйгамбәребез әйтте: «Хакыйкатьтә, әгәр дә син бу төнеңдә үлсәң, фитрый халәтеңдә (Аллаһка иманлы булып) үләрсең. Ә инде иртән тере булып торсаң, хәерлелекне (әҗер-савап) табырсың»

57 Сахих әл-Җәмигь әс-Сәгыйрь 4693

40 — «Аллаһның камил сүзләренә[58] Аның ачуыннан, җәзасыннан, колларының явызлыгыннан, шәйтаннарның вәсвәсәләреннән һәм аларның минем яныма килүләреннән сыенам»[59]

## 21 – Начар төш күргәндә нәрсә эшләргә

41 —

а) Сул якка 3 тапкыр төкерергә.

б) Аллаһ тәгаләгә шәйтаннан һәм күргән төшнең яманлыгыннан сыенырга (3 тапкыр)

в) Беркемгә дә сөйләмәскә.

г) Яткан ягын алыштырырга (сул якта яткан булса – уңга, һәм киресенчә)

42 — Теләсә торып намаз укырга.

## 22 – Витр намазындагы кунүт догасы

٤٣ – «اللَّهُمَّ إِيَّاكَ نَعْبُدُ، وَلَكَ نُصَلِّي وَنَسْجُدُ، وَإِلَيْكَ نَسْعَى وَنَحْفِدُ، نَرْجُو رَحْمَتَكَ وَنَخْشَى عَذَابَكَ، إِنَّ عَذَابَكَ بِالْكَافِرِينَ مُلْحَقٌ اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْتَعِينُكَ وَنَسْتَغْفِرُكَ، وَنُثْنِي عَلَيْكَ الْخَيْرَ وَلَا نَكْفُرُكَ، وَنُؤْمِنُ بِكَ وَنَخْضَعُ لَكَ، وَنَخْلَعُ مَنْ يَكْفُرُكَ»

***43 – /Аллаһүммә ийәкә нәгьбүдү үә ләкә нүсалли үә нәсҗүдү үә иләйкә нәсга үә нәхфидү нәрҗү рахмәтәкә үә нәхъшә гаҙәбәкә иннә гаҙәбәкә бил-кәфиринә мүлхәкъ. Аллаһүммә иннә нәстәгыйнүкә үә нәстәгьфирукә үә нүҫни галәйкәл-хайра үә лә нәкфүрукь, үә нү‘минү бикә үә нәхъдагү ләкә үә нәхъләгү мән йәкфүрукь/***

43 — «Әй Аллаһ! Сиңа гына гыйбадәт кылабыз, Сиңа

58 Кәүния һәм шәрьгыя сүзләр керә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин; аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

59 Әбү Дауыд 3893

гына намаз вә сәҗдә кылабыз. Сиңа таба омтылабыз вә ашыгабыз, Синең рәхмәтеңне сорыйбыз вә газабыңнан куркабыз, хакыйкатьтә, Синең газабыңа кәферләр дучар булачак. Әй Аллаһ! Дөреслектә, без Синең ярдәмеңне сорыйбыз, Синнән ярлыкау эстибез, нигъмәтең өчен Сине мактыйбыз, Сиңа көферлек кылмыйбыз, Сиңа иман китерәбез, Сиңа буйсынабыз һәм Сиңа көферлек кылучылардан баш тартабыз вә ваз кичәбез»[60]

## 23 – Тынычсызлык һәм ямансу билэп алганда укыла торган дога

٤٤ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ
وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ وَضَلَعِ الدَّيْنِ وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ»

***44 – /Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-һәмми үәл-хәзәни үәл-гаҗзи үәл-кәсәли үәл-бүхъли үәл-җүбни үә даләгыйд-дәйни үә галәбәтир-риҗәл/***

44 — «Әй Аллаһ! Мин, тынычсызлыктан һәм кайгыдан, гаҗизлектән һәм ялкаулыктан, саранлыктан һәм куркаклыктан, бурычның авырлыгыннан һәм кешеләрнең золым кылуларыннан, Сиңа сыенам»[61]

٤٥ – «اللَّهُمَّ إِنِّى عَبْدُكَ وَابْنُ عَبْدِكَ وَابْنُ أَمَتِكَ نَاصِيَتِى بِيَدِكَ مَاضٍ فِيَّ
حُكْمُكَ عَدْلٌ فِيَّ قَضَاؤُكَ أَسْأَلُكَ بِكُلِّ اسْمٍ هُوَ لَكَ سَمَّيْتَ بِهِ نَفْسَكَ أَوْ أَنْزَلْتَهُ
فِي كِتَابِكَ أَوْ عَلَّمْتَهُ أَحَداً مِنْ خَلْقِكَ أَوِ اسْتَأْثَرْتَ بِهِ فِى عِلْمِ الْغَيْبِ عِنْدَكَ
أَنْ تَجْعَلَ الْقُرْآنَ رَبِيعَ قَلْبِى وَنُورَ صَدْرِى وَجَلاَءَ حُزْنِى وَذَهَابَ هَمِّى»

***45 – /Аллаһүммә инни габдүк, үәбнү габдик, үәбнү әмәтик, нәсыяти биядик, мәдыйн фийә хүкмүк, гадлүн фийә када‘үк, әс‘әлүкә бикүллисмин һүә ләк, сәммәйтә биһи нәфсәк, әү әнзәлтәһү фи китәбик, әү галләмтәһү әхәдән мин халкыйкь, әүистә‘ҫәртә биһи фи гыйлмил-гайби гыйндәк, ән тәҗгаләл-Куръәнә рабигә калби үә нүра садри үә җәлә‘ә хүзни үә ҙәһәбә һәмми/***

60 әл-Бәйһәкый «әс-Сүнән әл-Күбра» 3269

61 Бохари 2893. Пәйгамбәребез бу доганы күп укый торган иде

45 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Синең колың, Синең колың булган ир-атның угълы һәм Синең колың булган хатын-кызның угълы. Мин тулысынча Синең кулыңда, Синең хөкемең минем өчен мәҗбүри тиешле, ә Синең миңа билгеләгән карарың гадел. Мин Синнән, Үзеңә Үзең исемләгән яки Китабыңда иңдергән яки мәхлукларыңның берсенә белгерткән яки Үзеңдә яшереп калдырган һәрбер исемең белән сорыйм; Коръәнне минем калебемнең язы ит, күкрәгемнең нуры ит, кайгымның бетү сәбәбе ит һәм тынычсызлыгымның китүе ит!»[62]

## 24 – Олы кайгы килгәндә укыла торган дога

٤٦ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ الْعَظِيمُ الْحَلِيمُ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ رَبُّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ، لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ رَبُّ السَّمَوَاتِ، وَرَبُّ الأَرْضِ، وَرَبُّ الْعَرْشِ الْكَرِيمِ»

***46 – /Лә иләһә илләАллаһүл-газыймүл-хәлим, лә иләһә илләАллаһү раббүл-гаршил-газыйм, лә иләһә илләАллаһү раббүс-сәмәүәти үә раббүл-әръдый үә раббүл-гаршил-кәрим/***

46 — «әл-Хәлим әл-Газыйм булучы Аллаһтан башка иләһ юк! Бөек гарешнең раббысы булган Аллаһтан башка иләһ юк! Күкләрнең, җирнең һәм кәрим көрсинең раббысы булган Аллаһтан башка иләһ юк!»[63]

٤٧ – «اللَّهُمَّ رَحْمَتَكَ أَرْجُو فَلاَ تَكِلْنِي إِلَى نَفْسِي طَرْفَةَ عَيْنٍ وَأَصْلِحْ لِي شَأْنِي كُلَّهُ لاَ إِلَهَ إِلاَّ أَنْتَ»

***47 – /Аллаһүммә рахмәтәкә әръҗү фәлә тәкилни илә нәфси тарфәтә гайн, үә әсълих ли шә‘ни күлләһү лә иләһә иллә әнт/***

47 — «Әй Аллаһ! Синең рәхмәтеңне эстим, мине үз-үземә күз ачып йомган мизгелгә генә дә калдырма.

62 Әхмәд «Мүснәд». Кем бу доганы укыса, һичшиксез Аллаһ аның ямансуын, тынычсызлыгын бетерер һәм шатлык китерер

63 Бохари 2893

Минем барча эшләремне ислах вә төзек кыл, Синнән башка иләһ юк!»[64]

## 25 – Дошман яки гаделсез хөкемдарлар белән очрашудан курыкканда укыла торган дога

٤٨ – «اللَّهُمَّ إِنَّا نَجْعَلُكَ فِى نُحُورِهِمْ وَنَعُوذُ بِكَ مِنْ شُرُورِهِمْ»

***48 – /Аллаһүммә иннә нәҗгалүкә фи нүхүриһим үә нәгүҙү бикә мин шүрүриһим/***

48 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, без Синнән аларны җиңәргә ярдәмеңне эстибез һәм аларның явызлыгыннан Сиңа сыенабыз»[65]

## 26 – Дошманга каршы укыла торган дога

٤٩ – «اللَّهُمَّ مُنْزِلَ الْكِتَابِ سَرِيعَ الْحِسَابِ، اللَّهُمَّ اهْزِمِ الأَحْزَابَ، اللَّهُمَّ اهْزِمْهُمْ وَزَلْزِلْهُمْ»

***49 – /Аллаһүммә мүнзиләл-китәби сәригаль-хисәб, Аллаһүммә иһзимил-әхзәб, Аллаһүммә иһзимһүм үә зәлзилһүм/***

49 — «Әй Китап (Коръән) иңдерүче вә тиз хисаб кылучы Аллаһ! Әй Аллаһ! Берләшкән дошман төркемнәрен тар-мар ит! Әй Аллаһ! Аларны тар-мар ит һәм тетрәт!»[66]

## 27 – Берәр кешедән курыкканда укыла торган дога

٥٠ – «اللَّهُمَّ اكْفِنِيهِمْ بِمَا شِئْتَ»

***50 – /Аллаһүммәкфиниһим бимә ши‘тә/***

50 — «Әй Аллаһ! Мине болардан Үзең теләгәнчә (алар-

64 Әбү Дауыд 5090

65 Әбү Дауыд 1537

66 Бохари 2933

ны газаплап) коткар!»[67]

## 28 – Бурычларны түләү өчен ярдәм сорап укыла торган дога

٥١ – «اللَّهُمَّ اكْفِنِى بِحَلاَلِكَ عَنْ حَرَامِكَ وَأَغْنِنِى بِفَضْلِكَ عَمَّنْ سِوَاكَ»

***51 – /Аллаһүммәкфини бихәләликә ган хәрамик, үә әгънини бифадъликә гаммән сиүәк/***

51 — «Әй Аллаһ! Синең хәләлең миңа җитеп Син хәрам кылган нәрсәгә керүдән котылдыр, һәм Үзеңнең фазыйләтең белән Синнән башкага мохтаҗ булудан коткар!»[68]

٥٢ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ بِكَ مِنَ الْهَمِّ وَالْحَزَنِ وَالْعَجْزِ وَالْكَسَلِ وَالْبُخْلِ وَالْجُبْنِ وَضَلَعِ الدَّيْنِ وَغَلَبَةِ الرِّجَالِ»

***52 – /Аллаһүммә инни әгүҙү бикә минәл-һәмми үәл-хәзәни үәл-гаҗзи үәл-кәсәли үәл-бүхли үәл-җүбни үә даләгыйд-дәйни үә галәбәтир-риҗәл/***

52 — «Әй Аллаһ! Мин, тынычсызлыктан һәм кайгыдан, гаҗизлектән һәм ялкаулыктан, саранлыктан һәм куркаклыктан, бурычның авырлыгыннан һәм кешеләрнең золым кылуларыннан, Сиңа сыенам»[69]

## 29 – Кешегә берәр эш авыр күренгәндә укыла торган дога

٥٣ – «اللَّهُمَّ لا سَهْلَ إِلَّا مَا جَعَلْتَهُ سَهْلاً وَأَنْتَ تَجْعَلُ الْحَزْنَ إذا شِئْتَ سَهْلاً»

***53 – /Аллаһүммә лә сәһлә иллә мә җәгалтәһү сәһлә, үә әнтә тәҗгалүл-хәзнә иҙә ши'тә сәһлә/***

53 — «Әй Аллаһ! Син җиңел кылган нәрсәдән башка җиңел һичнәрсә юк, һәм әгәр Син теләсәң, авырлыкны

67 Мөслим 3005

68 Тирмизи 3563. Әгәр синең тау кадәр бурычың булса да, Аллаһ сиңа аны түләргә ярдәм итәчәк

69 Бохари 2893. Пәйгамбәребез бу доганы күп укый торган иде

җиңел итәсең»[70]

## 30 – Гөнаһ кылган кеше нәрсә эшләргә һәм укырга тиеш

54 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә кешеләрдән берсе гөнаһ эшләсә, аннары тиешле рәвештә (сөннәтләре белән) таһәрат алып ике ракәгать намаз укыса һәм соңыннан Аллаһтан ярлыкауны сораса, Аллаһ тәгалә аны гафу итәр»[71]

## 31 – Кешегә берәр нәрсә ошамаганда яки бернәрсә дә эшли алмаган очракта укыла торган дога

٥٥ – «قَدَرُ اللَّهِ وَمَا شَاءَ فَعَلَ»

***55 – /Кадәруллаһи үә мә шә‘ фәгал/***

55 — «Бу Аллаһның тәкъдире, һәм Ул нәрсә теләде, шуны эшләде»[72]

## 32 – Баласы туган кешегә котлап әйтелә торган дога һәм аңа җавап

٥٦ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ فِي الْمَوْهُوبِ لَكَ وَشَكَرْتَ الْوَاهِبَ وَبَلَغَ أَشُدَّهُ وَرُزِقْتَ بِرَّهُ»

***56 – /БәракәАллаһү ләкә фил-мәүһүби ләкә үә***

---

70 Ибен Хиббән «Сахих» 2427

71 Әбү Дауыд 1521

72 Мөслим 2664. Пәйгамбәребез әйтте: «Көчле мөэмин Аллаһ каршында зәгыйфь мөэмингә караганда хәерлерәк һәм сөеклерәк, һәм аларның икесендә дә яхшылык бар. Сиңа файда китерә торган нәрсәгә хирыс бул һәм Аллаһтан ярдәм сора вә гаҗиз булма. Әгәр сиңа бер авырлык килсә: «Әгәр дә мин тегене һәм моны эшләгән булсамчы!», – дип әйтмә, бәлки: «Бу Аллаһның тәкъдире, һәм Ул нәрсә теләде, шуны эшләде», – диген. Чөнки «әгәр дә» дигән сүз, шәйтан эшенең ишеген ача

***шәкәртәл-уәһибә уә бәләга әшуддәһү уә рузикътә бирраһү/***

56 — «Сиңа бирелгән бүләктә Аллаһ сиңа бәракәт бирсен, һәм син бүләк бирүче Аллаһка шөкер ит. Ул бала бәлигъ булып, сиңа аның игелеген күрергә насыйп булсын!»

Бу сүзләр белән котланган кеше, болай дип җавап бирергә тиеш:

«بَارَكَ اللهُ لَكَ وَبَارَكَ عَلَيْكَ وَجَزَاكَ اللهُ خَيْراً وَرَزَقَكَ اللهُ مِثْلَهُ وَأَجْزَلَ ثَوَابَكَ»

***– /БәракәАллаһү ләкә уә бәракә галәйкә уә җәзәкә-Аллаһү хайран уә разәкакәАллаһү миҫләһү уә әҗзәкә ҫәүәбәк/***

— «Аллаһ сиңа бәракәт бирсен һәм сиңа бәракәт иңдерсен, вә Аллаһ сине хәерлесе белән бүләкләсен, вә шундый ук нәрсә белән ризыкландырсын һәм савабыңны арттырсын!»[73]

## 33 – Балаларны саклау өчен укыла торган дога

٥٧ – «أُعِيذُكُمَا بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّةِ مِنْ كُلِّ
شَيْطَانٍ وَهَامَّةٍ وَمِنْ كُلِّ عَيْنٍ لاَمَّةٍ»

***57 – /Үгыйҙукүмә би кәлимәтил-ләһит-тәммәти мин күлли шәйтанин уә һәммәтин уә мин күлли гайнин ләәммәһ/***

57 — «Аллаһның камил сүзләре сезне һәрбер шәйтаннан, хәшәрәттән һәм яман күздән сакласын дип, мин ул сүзләргә сыенам»[74]

73 «Әл-Әзкәр» ән-Нәүәүи

74 Бохари 3371. Аллаһның камил сүзләренә сыену мәгънәсен 40нчы дога астөшермәсеннән кара

## 34 – Авыруны зиярат кылганда укыла торган дога

٥٨ – «لاَ بَأْسَ طَهُورٌ إِنْ شَاءَ اللَّهُ»

***58 – /Лә бә‘сә таһүрун иншә‘Аллаһ/***
58 — «Зарар юк, пакьланерсең Аллаһ теләсә»[75]

٥٩ – «أَسْأَلُ اللهَ الْعَظِيمَ رَبَّ الْعَرْشِ الْعَظِيمِ أَنْ يَشْفِيَكَ»

***59 – /Әс‘әлүллаһәл-газыймә раббәл-гаршил-газыйми ән йәшфийәк/*** (җиде тапкыр әйтелә)
59 — «Бөек гарешнең Раббысы булган Бөек Аллаһтан сине шифаландыруын сорыйм»[76]

## 35 – Авыруны зиярат кылуның фазыйләте

60 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Иртә белән авырган мөселманның хәлен белергә барган мөселман өчен җитмеш мең фәрештә кичкә кадәр дога кылачаклар, әгәр ул (авыру янына) кич белән барса җитмеш мең фәрештә аның өчен иртәнгә кадәр дога кылачаклар, ә Җәннәттә аның өчен җимешләр җыелачак»[77]

## 36 – Яшәү өметен югалткан авыруның догасы

٦١ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِى وَارْحَمْنِى وَأَلْحِقْنِى بِالرَّفِيقِ الأَعْلَى»

***61 – /Аллаһүммәгьфирли үәрхәмни үә әлхикъни биррафикыйл-әгьлә/***
61 — «Әй Аллаһ! Мине гафу ит, миңа рәхимлек кыл һәм

75 Бохари 3616
76 Әбү Дауыд 3106. Мөселман, авыру булган һәм әҗәле җитмәгән кардәшенең хәлен белеп зиярат кылса, һәм 7 тапкыр ошбу доганы кабатласа, ул кешене Аллаһ тәгалә һичшиксез авыруыннан шифа кылыр
77 Тирмизи 969

мине әр-Рафикъ әл-Әгълә белән кушылдыр»[78]

## 37 – Үлүчегә тәлкыйнь[79] кылу

62 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:
— «Кемнең ахыргы сүзләре */Лә иләһә иллә Аллаһ/* булса, Җәннәткә керер»[80]

## 38 – Кайгы-хәсрәткә юлыккан кеше укый торган дога

٦٣ – «إِنَّا لِلَّهِ وَإِنَّا إِلَيْهِ رَاجِعُونَ اللَّهُمَّ أْجُرْنِى فِى مُصِيبَتِى وَأَخْلِفْ لِى خَيْرًا مِنْهَا»

***63 – /Иннә лилләһи үә иннә иләйһи раҗигүн, Аллаһүммә‘җүрни фи мүсыйбәти үә әхълиф ли хайран минһә/***

63 — «Хакыйкатьтә, без Аллаһныкы һәм Аңа кайтачакбыз. Әй Аллаһ! Бу кайгы-хәсрәтемдә мине саваплы ит, һәм миңа аннан да яхшыракны бир»[81]

## 39 – Мәетнең күзләрен йомдыргач укыла торган дога

٦٤ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِ(فُلَانٍ بِاسْمِهِ) وَارْفَعْ دَرَجَتَهُ فِى الْمَهْدِيِّينَ وَاخْلُفْهُ فِى عَقِبِهِ فِى الْغَابِرِينَ وَاغْفِرْ لَنَا وَلَهُ يَا رَبَّ الْعَالَمِينَ وَافْسَحْ لَهُ فِى قَبْرِهِ وَنَوِّرْ لَهُ فِيهِ»

***64 – /Аллаһүммәгьфир ли (...)[82] үәръфәгь дәраҗәтәһү***

---

78 Бохари 5672. «әр-Рафикъ әл-Әгълә» монда яки Аллаһ тәгалә, чөнки бу аның күркәм исемнәре, яки пәйгамбәрләр, тугрылар, шәһидләр һәм изгеләр

79 Үлүче кешегә, иман кәлимәсен аның янында кабатлап торып, әйтергә ярдәм итү

80 Әбү Дауыд 3116

81 Мөслим 918. Кем бу доганы укыса, һичшиксез Аллаһ аны кайгы-хәсрәте өчен саваплы итәр һәм аның урынына яхшыракны бирер

82 Бу урында мәетнең исемен әйтә

***фил-мәһдиийин, үәхълуфһү фи гакыйбиһи фил-габирин, үәгъфир ләнә үә ләһү йә раббәл-галәмин, үәфсәх ләһү фи кабриһи үә нәүүир ләһү фиһ/***

64 — «Әй Аллаһ! Фәләнне ( мәетнең исеме әйтелә) ярлыка һәм аның дәрәҗәсен һидәятлеләр арасында күтәр. Аннан соң калганнарга, аны икенче белән алыштыр. Әй галәмнәрнең Раббысы, безне һәм аны гафу ит! Аның каберен киң кыл һәм аңа аны нурландыр!»[83]

## 40 – Җеназа намазы догасы

٦٥ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لِحَيِّنَا وَمَيِّتِنَا وَشَاهِدِنَا وَغَائِبِنَا وَصَغِيرِنَا وَكَبِيرِنَا وَذَكَرِنَا وَأُنْثَانَا اللَّهُمَّ مَنْ أَحْيَيْتَهُ مِنَّا فَأَحْيِهِ عَلَى الإِسْلاَمِ وَمَنْ تَوَفَّيْتَهُ مِنَّا فَتَوَفَّهُ عَلَى الإِيمَانِ اللَّهُمَّ لاَ تَحْرِمْنَا أَجْرَهُ وَلاَ تُضِلَّنَا بَعْدَهُ»

***65 – /Аллаһүммәгьфир лихәйинә үә мәйитинә үә шәһидинә үә гаибинә үә сагыйринә үә кәбиринә үә ҙәкәринә үә үнçәнә, Аллаһүммә мән әхйәйтәһү миннә фә‘әхйиһи галәл-Исләми үә мән тәүәффәйтәһү миннә фәтәүәффәһү галәл-имән, Аллаһүммә лә тәхримнә әҗраһү үә лә түдыйлләнә бәгьдәһү/***

65 — «Әй Аллаһ! Безнең исәннәребезне вә үлгәннәребезне, монда булучыларыбызны вә монда булмаучыларыбызны, сабыйларыбызны вә олыларыбызны, ирләребезне вә хатын-кызларыбызны гафу ит! Әй Аллаһ! Безнең арадагыларның кайсысына тормыш бирсәң – аңа Ислам тормышы бир, ә безнең арадан кемне вафат кылсаң – аны Иманда вафат кылдыр! Әй Аллаһ! Безне аның савабыннан[84] мәхрүм итмә, һәм аннан соң безне адаштырма!»[85]

---

83 Мөслим 920

84 Ягъни, бу кеше вафат булганнан соң сабырлык күрсәткән өчен безне савабтан мәхрүм итмә

85 Ибен Мәҗәһ 1498

## 41 – Сабый баланың җеназасында укыла торган дога

٦٦ – «اللَّهُمَّ اجْعَلْهُ لَنَا فَرَطًا وَسَلَفًا وَأَجْرًا»

***66 – /Аллаһүммәҗгалһү ләнә фәратан үә сәләфән үә әҗра/***

66 — «Әй Аллаһ! Бу сабый Җәннәткә әти-әниләреннән алда узып аларны каршы алучы булсын, бездән элгәре булсын һәм безгә килгән кайгыда сабырлыгыбыз өчен әҗер-савап булсын!»[86]

## 42 – Тәгъзия[87] догасы

٦٧ – «إِنَّ لِلَّهِ مَا أَخَذَ وَلَهُ مَا أَعْطَى وَكُلُّ شَيْءٍ عِنْدَهُ بِأَجَلٍ مُسَمًّى ... فَلْتَصْبِرْ وَلْتَحْتَسِبْ»

***67 – /Иннә лиләһи мә әхаҙә үә ләһү мә әгьта үә куллү шәй'ин гыйндәһү би әҗәлин мүсәммә ... фәлтәсъбир үәлтәхтәсиб/***

67 — «Хакыйкатьтә, Аллаһ тәгалә алганы да, биргәне дә – Аныкы, һәм һәрнәрсәгә Ул әҗәл-вакытын билгеләде ... Шулай булгач, сабырлык күрсәт һәм Аллаһтан әҗер-савап өмет ит!»[88]

## 43 – Мәетне кабергә куйганда укыла торган дога

٦٨ – «بِسْمِ اللَّهِ وَعَلَى مِلَّةِ رَسُولِ اللَّهِ»

***68 – /Бисмилләһ, үә галә милләти расүлилләһ/***

68 — «Аллаһ исеме белән, һәм Аллаһ расүленең милләтенә муафыйк итеп»[89]

---

86 Бохари 65нче бәб

87 Үлгән кешенең якыннарының һәм туганнарының кайгысын уртаклашу, юату

88 Бохари 1284

89 Ибен Мәҗәһ 1550

## 44 – Мәетне җирләгәч укыла торган дога

٦٩ – «اللَّهُمَّ اغْفِرْ لَهُ اللَّهُمَّ ثَبِّتْهُ»

***69 – /Аллаһүммәгьфир ләһү, Аллаһүммә ҫәббитһү/***

69 — «Әй Аллаһ! Аның гөнаһларын ярлыка! Әй Аллаһ! Аны сабит кыл!»[90]

## 45 – Каберләрне зиярат кылганда укыла торган дога

٧٠ – «السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ أَهْلَ الدِّيَارِ مِنَ الْمُؤْمِنِينَ وَالْمُسْلِمِينَ
وَإِنَّا إِنْ شَاءَ اللَّهُ لَلاَحِقُونَ أَسْأَلُ اللَّهَ لَنَا وَلَكُمُ الْعَافِيَةَ»

***70 – /Әссәләмү галәйкүм әһләд-дияри минәл-мү‘мининә үәл-мүслимин, үә иннә иншә‘Аллаһү ләләһикун, әс‘әлүллаһә ләнә үә ләкүмүл-гафияһ/***

70 — «Мөэминнәр һәм мөселманнар булган кабер әһелләренә сәлам булсын! Хакыйкатьтә, Аллаһ теләсә без дә сезгә кушылырбыз. Үзебезгә һәм сезгә Аллаһтан иминлек сорыйм»[91]

## 46 – Җил чыкканда укыла торган дога

٧١ – «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَخَيْرَ مَا فِيهَا وَخَيْرَ مَا أُرْسِلَتْ
بِهِ وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَشَرِّ مَا فِيهَا وَشَرِّ مَا أُرْسِلَتْ بِهِ»

***71 – /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә хайраһә үә хайра мә фиһә үә хайра мә үръсиләт биһи үә әгүҙү бикә мин шәрриһә үә шәрри мә фиһә үә шәрри мә үръсиләт биһ/***

71 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, мин Синнән бу җилнең хәерен, ул алып килгән нәрсәнең хәерен һәм аның белән җибәрелгән нәрсәнең хәерен сорыйм. Һәм мин аның явызлыгыннан, ул алып килгән нәрсәнең явызлыгыннан

90 Әбү Дауыд 3221. Пәйгамбәребез мәетне җирләгәннән соң, кабер янына басты һәм: «Кардәшегезгә ярлыкау һәм сабит булуны сорагыз, хакыйкатьтә, ул хәзер сорала», – диде

91 Мөслим 975

һәм аның белән җибәрелгән нәрсәнең явызлыгыннан Сиңа сыенам»[92]

## 47 – Күк күкрәгәндә укыла торган дога

٧٢ – «سُبْحَانَ الَّذِى يُسَبِّحُ الرَّعْدُ بِحَمْدِهِ وَالْمَلاَئِكَةُ مِنْ خِيفَتِهِ»

***72 – /Сүбхәнәлләҙи йүсәббихүр-рагьдү бихәмдиһи үәл-мәлә‘икәтү мин хыйфәтиһ/***

72 — «Күкрәү һәм фәрештәләр Аннан куркып мактау тәсбихләре әйткән Аллаһ, һәркимчелектән пакь!»[93]

## 48 – Яңгыр сораганда укыла торган дога

٧٣ – «اللَّهُمَّ اسْقِ عِبَادَكَ وَبَهَائِمَكَ وَانْشُرْ رَحْمَتَكَ وَأَحْيِ بَلَدَكَ الْمَيِّتَ»

***73 – /Аллаһүммәскый гыйбәдәкә үә бәһә‘имәкә үәншүр рахмәтәкә үә әхйи бәләдәкәл-мәйит/***

73 — «Әй Аллаһ! Үзеңнең колларыңны һәм хайваннарыңны сугар. Үзеңнең рәхмәтеңне җәй һәм мәет булган җиреңне терелт!»[94]

## 49 – Яңгыр яуганда укыла торган дога

٧٤ – «اللَّهُمَّ صَيِّبًا نَافِعًا»

***74 – /Аллаһүммә сайибән нәфиган/***

74 — «Әй Аллаһ! Бу яңгыр файда китерсен!»[95]

## 50 – Яңгыр яуганнән соң укыла торган дога

٧٥ – «مُطِرْنَا بِفَضْلِ اللَّهِ وَرَحْمَتِهِ»

***75 – /Мүтыйрнә бифәдълилләһи үә рахмәтиһ/***

---

92 Мөслим 899
93 Әл-Мүәтта 3641
94 Әбү Дауыд 1169
95 Бохари 1032

75 — «Аллаһның фазыйләте вә рәхмәте илә безгә яңгыр яуды»[96]

## 51 – Берөзлексез яуган яңгырны туктатуны сорап укыла торган дога

٧٦ – «اللَّهُمَّ حَوَالَيْنَا وَلاَ عَلَيْنَا، اللَّهُمَّ عَلَى الآكَامِ
وَالظِّرَابِ وَبُطُونِ الأَوْدِيَةِ وَمَنَابِتِ الشَّجَرِ»

***76 – /Аллаһүммә хәүәлинә үә лә галәйнә, Аллаһүммә галәл-әкәми үәҙҙыйраби үә бүтунил-әүдияти үә мәнәбитиш-шәҗәр/***

76 — «Әй Аллаһ! Безгә түгел, ә тирә-юньгә яудыр. Әй Аллаһ! Калкулыкларга һәм тауларга, үзәнлекләргә һәм агачлар үскән җирләргә яудыр!»[97]

## 52 – Яңа туган ай күргәндә укыла торган дога

٧٧ – «اللَّهُمَّ أَهْلِلْهُ عَلَيْنَا بِالْيُمْنِ وَالإِيمَانِ
وَالسَّلاَمَةِ وَالإِسْلاَمِ رَبِّى وَرَبُّكَ اللَّهُ»

***77 – /Аллаһүммә әһлилһү галәйнә бил-йүмни үәл-имәни үәссәләмәти үәл-ислəм, рабби үә раббүкә Аллаһ/***

77 — «Әй Аллаһ! Бу айны безнең өстебезгә иминлек һәм Иман белән, сәламәтлек һәм Ислам белән китер. Безнең Раббыбыз һәм синең Раббың – Аллаһ!»[98]

## 53 – Авыз ачканда укый торган дога

٧٨ – «ذَهَبَ الظَّمَأُ وَابْتَلَّتِ الْعُرُوقُ وَثَبَتَ الأَجْرُ إِنْ شَاءَ اللَّهُ»

***78 – /Ҙәһәбәҙҙамә‘ү үәбтәлләтил-гуруку үә ҫәбәтәл-әҗру иншә‘Аллаһ/***

---

96 Бохари 846
97 Бохари 1013
98 Тирмизи 3451

78 — «Сусау китте, кан тамырлары юешләнде һәм әҗер-савап та булды иншә‘Аллаһ»[99]

## 54 – Ашар алдыннан укый торган дога

79 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Ашый башлаганчы сезнең һәркайсыгыз ***/Бисмилләһ/*** — дип, Аллаһның исемен искә алсын, әгәр ул Аллаһ тәгаләнең исемен искә алырга онытса, ***/Бисмилләһи фи әүүәлиһи үә әхыйриһи!/*** әүвәлдә һәм ахырда Аллаһ исеме белән! — дисен».[100]

## 55 – Ашаганнан соң укыла торган дога

٨٠ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى أَطْعَمَنِى هَذَا وَرَزَقَنِيهِ مِنْ غَيْرِ حَوْلٍ مِنِّى وَلاَ قُوَّةٍ»

***80 – /Әлхәмдүлилләһил-ләҙи әтъгәмәни һәҙә үә разәканиһи мин гайри хәүлин минни үә лә куүәһ/***

80 — «Минем хәлем һәм көчем кулланылмыйча, мине моның белән ашатучы һәм ризыкландыручы Аллаһка барча мактау булсын!»[101]

## 56 – Кунакның мәҗлес хуҗасына карата кыла торган догасы

٨١ – «اللَّهُمَّ بَارِكْ لَهُمْ فِى مَا رَزَقْتَهُمْ وَاغْفِرْ لَهُمْ وَارْحَمْهُمْ»

***81 – /Аллаһүммә бәрик ләһүм фи мә разәкътәһүм үәгьфир ләһүм үәръхәмһүм/***

81 — «Әй Аллаһ! Син аларны ризыкландырган нәрсәләргә бәракәт бир, һәм аларны ярлыка вә аларга рәхимлек кыл»[102]

---

99 Әбү Дауыд 2357

100 Тирмизи 1858

101 Тирмизи 3458. Ашаганнан соң бу доганы укучының алдагы гөнаһлары гафу ителә

102 Мөслим 2042

## 57 – Беренче өлгергән җимешләрне күргәч укыла торган дога

٨٢ – «اللَّهُمَّ بَارِكْ لَنَا فِى ثَمَرِنَا وَبَارِكْ لَنَا فِى مَدِينَتِنَا
وَبَارِكْ لَنَا فِى صَاعِنَا وَبَارِكْ لَنَا فِى مُدِّنَا»

***82 – /Аллаһүммә бәрик ләнә фи çәмәринә үә бәрик ләнә фи мәдинәтинә үә бәрик ләнә фи сагыйнә үә бәрик ләнә фи мүддинә/***

82 — «Әй Аллаһ! Безнең җимешләребезне бәракәтле кыл, һәм безнең шәһәребезне бәракәтле кыл, һәм безнең сагьларыбызны[103] бәракәтле кыл, һәм безнең мүдләребезне[104] бәракәтле кыл!»[105]

## 58 – Төчкергәннән соң укыла торган дога

83 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә берәрегез төчкерсә: «Аллаһ тәгаләгә мактау булсын!» ***/Әлхәмдүлилләһ/*** — дип әйтсен, һәм аның кардәше яки аның юлдашы аңа: «Сине Аллаһ ярлыкасын!» ***/ЙәрхәмүкәАллаһ!/*** — дисен. Ә әгәр ул аңа: «Аллаһ сине ярлыкасын!» /ЙәрхәмүкәАллаһ!/ — дип әйтсә, төчкерүче аңа җавап итеп: «Аллаһ сезгә һидәять бирсен һәм барлык эшләрегезне яхшыртсын!» ***/Йәһдикүмуллаһү үә йуслих бәләкүм!/*** — дип әйтсен»[106]

## 59 – Яңа өйләнгәннәрне котлап укыла торган дога

٨٤ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ وَبَارَكَ عَلَيْكَ وَجَمَعَ بَيْنَكُمَا فِى خَيْرٍ»

***84 – /Бәракәллаһү ләкә үә бәрәкә галәйкә үә җәмәга бәйнәкүмә фи хайр/***

---

103 Үлчәү күләме
104 Үлчәү күләме
105 Мөслим 1373
106 Бохари 6224

84 — «Аллаһ сиңа бәракәт бирсен вә бәракәт иңдерсен, һәм сезне хәере белән берләштерсен!»[107]

## 60 – Өйләнгән кеше укый торган дога

٨٥ ــ «اللَّهُمَّ إِنِّى أَسْأَلُكَ خَيْرَهَا وَخَيْرَ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ
وَأَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا وَمِنْ شَرِّ مَا جَبَلْتَهَا عَلَيْهِ»

***85 – /Аллаһүммә инни әс‘әлүкә хайраһә үә хайра мә җәбәлтәһә галәйһи үә әгүҙү бикә мин шәрриһә үә шәрри мә җәбәлтәһә галәйһи/***

85 — «Әй Аллаһ! Мин Синнән аның яхшылыгын вә аңарда Син халикъ кылган яхшылыкны сорыйм, һәм аның яманлыгыннан вә аңарда Син халикъ кылган яманлыктан Сиңа сыенам»[108]

## 61 – Хатын белән җенси якынлык кылыр алдыннан укый торган дога

٨٦ ــ «بِسْمِ اللَّهِ اللَّهُمَّ جَنِّبْنَا الشَّيْطَانَ وَجَنِّبِ الشَّيْطَانَ مَا رَزَقْتَنَا»

***86 – /Бисмилләһ, Аллаһүммә җәннибнәш-шәйтанә үә җәннибиш-шәйтанә мә разәкътәнә/***

86 — «Әй Аллаһ! Бездән шәйтанны ерагайт, һәм безгә биргән баладан шәйтанны ерагайт!»[109]

## 62 – Ачуланганда укыла торган дога

٨٧ ــ «أَعُوذُ بِاللَّهِ مِنَ الشَّيْطَانِ الرَّجِيمِ»

***87 – /Әгүҙү билләһи минәш-шәйтанир-ражим/***

87 — «Барча рәхмәттән сөрелмеш шәйтаннан, Аллаһка

---

107 Әбү Дауыд 2130

108 Әбү Дауыд 2160. Маңгай чәченнән тотып бәракәт эсти яки шушы доганы укый

109 Бохари 6388. Алар ошбу җенси якынлашуларыннан балага узса, ул балага шәйтан беркайчан да зыян итә алмый

сыенам»[110]

## 63 – Бәла-казага ирешүчене күргәндә укыла торган дога

٨٨ – «الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى عَافَانِى مِمَّا ابْتَلاَكَ بِهِ
وَفَضَّلَنِى عَلَى كَثِيرٍ مِمَّنْ خَلَقَ تَفْضِيلاً»

***88 – /Әлхәмдүлилләһилләҙи гафәни миммәбтәләкә биһи үә фәдъдаләни галә кәҫирим-миммән халәка тәфдыйлә/***

88 — «Сине сынаган нәрсәдән мине саклап калган һәм күп кенә мәхлукатларга караганда миңа өстенлек күрсәткән Аллаһка барча мактаулар булсын!»[111]

## 64 – Нинди дә булса җыенда яки мәҗлестә укыла торган дога

٨٩ – «رَبِّ اغْفِرْ لِى وَتُبْ عَلَىَّ إِنَّكَ أَنْتَ التَّوَّابُ الْغَفُورُ»

***89 – /Раббигьфирли үә түб галәййә иннәкә әнтәт-тәүүәбүл-гафүръ/***

89 — «Әй Раббым! Мине гафу ит һәм тәүбәмне кабул ит, хакыйкатьтә, Син тәүбәләрне кабул итүче һәм ярлыкаучы»[112]

## 65 – Җыен яки мәҗлес ахырында укыла торган дога

٩٠ – «سُبْحَانَكَ اللَّهُمَّ وَبِحَمْدِكَ أَشْهَدُ أَنْ لاَ إِلَهَ
إِلاَّ أَنْتَ أَسْتَغْفِرُكَ وَأَتُوبُ إِلَيْكَ»

---

110 Бохари 6515

111 Тирмизи 3431. Кем, бәла ирешкән кешене күргәннән соң ошбу доганы укыса, аңа бу бәла ирешмәс

112 Тирмизи 3434. Пәйгамбәребез берәр җыенда яки мәҗлестә булса, аннан торып киткәнче ошбу доганы 100 тапкыр әйтә иде

***90 – /СүбхәнәкәАллаһуммә үә бихәмдик, әшһәдү әллә иләһә иллә әнт, әстәгьфирукә үә әтүбү иләйк/***

90 — «Әй Аллаһ! Син барча кимчелектән пакьсең һәм Сиңа барча мактау! Синнән башка иләһ юк дип шәһидлек кылам. Синнән ярлыкау сорыйм һәм Сиңа тәүбә итәм!»[113]

## 66 – Сиңа яхшылык эшләгән кешегә әйтелә торган дога

٩١ – «جَزَاكَ اللَّهُ خَيْرًا»

***91 – /ҖәзәкәАллаһү хайра/***

91 — «Аллаһ сиңа хәерле бәясен бирсен!»[114]

## 67 – Сиңа үзенең акча-байлыгын тәкъдим итүче кешегә укыла торган дога

٩٢ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ فِى أَهْلِكَ وَمَالِكَ»

***92 – /БәракәАллаһү ләкә фи әһликә үә мәлик/***

92 — «Аллаһ синең гаиләңдә дә, байлыгыңда да бәракәт бирсен!»[115]

## 68 – Бурычны кайтарганда укыла торган дога

٩٣ – «بَارَكَ اللَّهُ لَكَ فِى أَهْلِكَ وَمَالِكَ إِنَّمَا جَزَاءُ السَّلَفِ الْحَمْدُ وَالأَدَاءُ»

***93 – /БәракәАллаһү ләкә фи әһликә үә мәлик, иннмә җәзә'үс-сәләфил-хәмдү үәл-әдә'/***

93 — «Аллаһ синең гаиләңдә дә, байлыгыңда да бәракәт бирсен! Хакыйкатьтә, бурычка бирүне бәяләү – мактау һәм бурычны кайтару белән»[116]

113 Әбү Дауыд 4859. Бу дога җыен яки мәҗлестәге гөнаһлар өчен йолу (кәффәрат)

114 Тирмизи 2035

115 Бохари 2049

116 Нәсәи 4683

## 69 – Ширектән курыкканда укыла торган дога

٩٤ – «اللَّهُمَّ إِنِّي أَعُوذُ بِكَ أَنْ أُشْرِكَ بِكَ وَأَنَا أَعْلَمُ وَأَسْتَغْفِرُكَ لِمَا لَا أَعْلَمُ»

***94 – /Аллаһүммә инни әгүзү бикә ән үшрикә бикә үә әнә әгьләм, үә әстәгьфирукә лимә лә әгьләм/***

94 — «Әй Аллаһ! Хакыйкатьтә, беләторып Сиңа ширек кылудан Сиңа сыенам, һәм белми торган нәрсәләрдән Синнән гафу үтенәм!»[117]

## 70 – Әгәр дә берәү: «Аллаһ сиңа бәракәт бирсен!» /БәракәАллаһү фикә/ – дисә, ничек җавап бирелә

٩٥ – «وَ فِيكَ بَارَكَ اللَّهُ»

***95 – /Үә фикә бәрәкәАллаһ/***

95 — «Сиңа да Аллаһ бәракәт бирсен!»

## 71 – Машинага, хайванга яки нәрсәгә булса да утырганда укыла торган дога

٩٦ – «بِسْمِ اللَّهِ، الْحَمْدُ لِلَّهِ، سُبْحَانَ الَّذِى سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا لَهُ مُقْرِنِينَ
وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنْقَلِبُونَ، الْحَمْدُ لِلَّهِ (ثَلاَثَ مَرَّاتٍ) اللَّهُ أَكْبَرُ (ثَلاَثَ مَرَّاتٍ)
سُبْحَانَكَ إِنِّى ظَلَمْتُ نَفْسِى فَاغْفِرْ لِى فَإِنَّهُ لاَ يَغْفِرُ الذُّنُوبَ إِلاَّ أَنْتَ»

***96 – /Бисмилләһ, әлхәмдүлилләһ, сүбхәнәлләҙи сәххара ләнә һәҙә үә мә күннә ләһү мукъринин, үә иннә илә раббинә ләмүнкалибүн, әлхәмдүлилләһ, әлхәмдүлилләһ, әлхәмдүлилләһ, Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ, Аллаһү әкбәръ, сүбхәнәкә инни ҙаләмтү нәфси фәгьфирли фә‘иннәһү лә йәгъфируҙ-ҙүнүбә илләә әнт/***

96 — «Аллаһ исеме белән. Барча мактау Аллаһка! Безгә моны буйсындырган Аллаһ һәр кимчелектән пакь, без бит үзебез аны булдыра ала торган түгел. Хакыйкатьтә,

117 Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагыйрь 3731

без Раббыбызга кайтачакбыз![118] Барча мактау Аллаhка! Барча мактау Аллаhка! Барча мактау Аллаhка! Аллаh бөек! Аллаh бөек! Аллаh бөек! Син hәр кимчелектән пакь! Әй Аллаh! Хакыйкатьтә, мин үземә золым кылдым, мине ярлыка. Хакыйкатьтә, Синнән башка гөнаhларны ярлыкаучы юк!»[119]

## 72 – Сәфәр догасы

٩٧ – «اللَّهُ أَكْبَرُ، اللَّهُ أَكْبَرُ، اللَّهُ أَكْبَرُ، سُبْحَانَ الَّذِى سَخَّرَ لَنَا هَذَا وَمَا كُنَّا
لَهُ مُقْرِنِينَ وَإِنَّا إِلَى رَبِّنَا لَمُنْقَلِبُونَ، اللَّهُمَّ إِنَّا نَسْأَلُكَ فِى سَفَرِنَا هَذَا الْبِرَّ
وَالتَّقْوَى وَمِنَ الْعَمَلِ مَا تَرْضَى اللَّهُمَّ هَوِّنْ عَلَيْنَا سَفَرَنَا هَذَا وَاطْوِ عَنَّا
بُعْدَهُ اللَّهُمَّ أَنْتَ الصَّاحِبُ فِى السَّفَرِ وَالْخَلِيفَةُ فِى الأَهْلِ اللَّهُمَّ إِنِّى أَعُوذُ
بِكَ مِنْ وَعْثَاءِ السَّفَرِ وَكَآبَةِ الْمَنْظَرِ وَسُوءِ الْمُنْقَلَبِ فِى الْمَالِ وَالأَهْلِ»

***97 – /Аллаhү әкбәръ, Аллаhү әкбәръ, Аллаhү әкбәръ! Сүбхәнәлләҙи сәххара ләнә hәҙә үә мә күннә ләhү мукъринин, үә иннә илә раббинә ләмүнкалибүн! Аллаhүммә, иннә нәс‘әлүкә фи сәфәринә hәҙәл-бирра үәт-тәкъүә үә минәл-гамәли мә тәръда. Аллаhүммә, hәүүин галәйнә сәфәранә hәҙә, үәтуи ганнә бүгдәh! Аллаhүммә әнтәс-сахибү фис-сәфәр, үәл-халифәтү фил-әhл. Аллаhүммә инни әгүҙү бикә мин үәгҫә‘ис-сәфәр, үә кә‘әәбәтил-мәнҙар, үә сү‘ил-мүнкаләби фил-мәли үәл-әhл/***

97 — «Аллаh бөек! Аллаh бөек! Аллаh бөек! Безгә моны буйсындырган Аллаh hәр кимчелектән пакь, без бит үзебез аны булдыра ала торган түгел. Хакыйкатьтә, без Раббыбызга кайтачакбыз! Әй Аллаh! Дөреслектә, без Синнән бу сәфәребездә изгелек hәм тәкъвалык, шулай ук Син риза булырлык гамәлләрне үтәүне сорыйбыз! Әй Аллаh! Бу сәфәребезне безнең өчен җиңеләйт hәм аныңераклыгын безнең өчен кыскарт! Әй Аллаh! Син бу сәфәрдә юлдаш hәм гаиләнең халифе. Әй Аллаh!

118 әз-Зухруф 13-14
119 Әбү Дауыд 2602

Дөреслектә, мин сәфәрнең авырлыкларыннан, күреп төшенкелеккә китерә торган нәрсәләрдән, мал һәм гаилә белән була ала торган барлык начарлыктан Сиңа сыенам!»

Кайтканда исә ул шушы сүзләргә түбәндәгене өстәп әйтә:

«آيِبُونَ تَائِبُونَ عَابِدُونَ لِرَبِّنَا حَامِدُونَ»

***– /Әйибүнә тә‘ибүнә габидүн, лираббинә хәмидүн/***

— «Без кайтабыз, тәүбә итәбез, гыйбадәт кылабыз һәм Раббыбызны мактыйбыз!»[120]

## 73 – Шәһәргә яки авылга кергәндә укыла торган дога

٩٨ – «اللَّهُمَّ رَبَّ السَّمَاوَاتِ السَّبْعِ وَمَا أَظْلَلْنَ، وَرَبَّ الأَرَضِينَ السَّبْعِ وَمَا أَقْلَلْنَ، وَرَبَّ الشَّيَاطِينِ وَمَا أَضْلَلْنَ، وَرَبَّ الرِّيَاحِ وَمَا ذَرَيْنَ، أَسْأَلُكَ خَيْرَ هَذِهِ الْقَرْيَةِ، وَخَيْرَ أَهْلِهَا، وَخَيْرَ مَا فِيهَا، وَنَعُوذُ بِكَ مِنْ شَرِّهَا، وَشَرِّ أَهْلِهَا، وَشَرِّ مَا فِيهَا»

***98 – /Аллаһүммә раббәс-сәмәүәтис-сәбги үә мә әҙълəлнә үә раббәл-әрадыйнәс-сәбги үә мә әкъләлнә үә раббәш-шәйәтыйни үә мә әдъләлнә үә раббәр-рияхи үә мә ҙәрайнә. Әс‘әлүкә хайра һәҙиһил-карьяти үә хайра әһлиһә үә хайра мә фиһә, үә әгүҙү бикә мин шәрриһә үә шәрри әһлиһә үә шәрри мә фиһә/***

98 — «Әй Аллаһ! Син, җиде кат күкләрнең һәм алар каплаган нәрсәләрнең Раббысы. Син, җиде кат җирләрнең һәм алар күтәреп торган нәрсәләрнең Раббысы. Син, шәйтаннарның һәм алар адаштырганнарның Раббысы. Син, җилләрнең һәм алар очырткан-туздырган нәрсәләрнең Раббысы. Мин, Синнән бу авылның яхшылыгын, аның яшәүчеләрнең яхшылыгын һәм аның эчендәге яхшылыкны сорыйм. Һәм бу авылның яманлыгыннан, аның яшәүчеләренең яманлыгыннан

120 Мөслим 1342

һәм аның эчендәге яманлыктан Сиңа сыенам!»[121]

## 74 – Базарга кергәндә укыла торган дога

٩٩ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ وَحْدَهُ لاَ شَرِيكَ لَهُ لَهُ الْمُلْكُ وَلَهُ الْحَمْدُ يُحْيِى
وَيُمِيتُ وَهُوَ حَىٌّ لاَ يَمُوتُ بِيَدِهِ الْخَيْرُ وَهُوَ عَلَى كُلِّ شَيْءٍ قَدِيرٌ»

***99 – /Лә иләһә иллә Аллаһү үәхдәһү лә шәрикә ләһ, ләһүл-мүлкү үә ләһүл-хәмд, йүхйи үә йүмиту үә һүә хййүн лә йәмүт, бийдиһил-хайр, үә һүә галә күлли шәй'ин кадир/***

99 — «Аллаһтан башка һич иләһ юк һәм Ул бер Үзе генә, Аның тиңдәше юк! Аңа гына барча патшалык вә Аңа гына барча мактау! Ул терелəндерә вә үлеләндерә һәм Ул даими тере вә үлми, яхшылык Аның кулында һәм Ул бар нәрсәгә кадир!»[122]

## 75 – Менге ат кебек атланып йөри торган хайван абынса укыла торган дога

١٠٠ – «بِسْمِ اللَّهِ»

***100 – /Бисмилләһ/***

100 — «Аллаһ исеме белән»[123]

## 76 – Мөсафирның мөкыймга[124] укый торган догасы

١٠١ – «أَسْتَوْدِعُكَ اللَّهَ الَّذِى لاَ تَضِيعُ وَدَائِعُهُ»

***101 – /ӘстәүдигукәАллаһ, әлләҙи лә тәдыйгу үәдә'игуһ/***

121 әл-Хәким «әл-Мүстәдрак»

122 Тирмизи 3429. Кем базарга кергәндә ошбу доганы укыса, ул кешегә Аллаһ тәгалә бер миллион изгелек яза, һәм аннан бер миллион яманлыкны җуя һәм аңа Җәннәттә йорт булдыра

123 Әбү Дауыд 4982

124 Юлчының өйдә калучыга

101 — «Мин сине Аллаһка тапшырам! Аңарда сакларга тапшырылган нәрсә югалмый»[125]

## 77 – Мөкыймның мөсафирга укый торган догасы

١٠٢ – «أَسْتَوْدِعُ اللَّهَ دِينَكَ وَأَمَانَتَكَ وَخَوَاتِيمَ عَمَلِكَ»

***102 – /Әстәүдигуллаһә динәкә үә әмәнәтәкә үә хаүәтимә гамәлик/***

102 — «Мин Аллаһка синең динеңне, әманәтеңне һәм эшеңнең ахыр нәтиҗәләрен тапшырам»[126]

١٠٣ – «زَوَّدَكَ اللَّهُ التَّقْوَى وَغَفَرَ ذَنْبَكَ وَيَسَّرَ لَكَ الْخَيْرَ حَيْثُمَا كُنْتَ»

***103 – /ЗәүүәдәкәАллаһүт-тәкъүә үә гафәра ҙәнбәк, үә йәссәра ләкәл-хайра хәйҫүмә күнтә/***

103 — «Аллаһ синең тәкъвалыгыңны арттырсын, гөнаһыңны ярлыкасың һәм кайда гына булсаң да сиңа изгелекне җиңеләйтсен»[127]

## 78 – Сәфәрдә тәкбир һәм тәсбих

104 — Җәбир ﵁ әйтте:

— «Без, калкулыкка менгән кебек өскә таба менгәндә: ***/Аллаһү әкбәръ/*** «Аллаһ һәрнәрсәдән бөек», — дип әйтә идек, ә аска таба төшкәндә: ***/СүбхәнәАллаһ/*** «Аллаһ барча кимчелектән пакь», — дип әйтә идек»[128]

## 79 – Сәфәрдә чакта яки башка вакытта берәр өйдә тукталганда укыла торган дога

١٠٥ – «أَعُوذُ بِكَلِمَاتِ اللَّهِ التَّامَّاتِ مِنْ شَرِّ مَا خَلَقَ»

125 Ибен Мәҗәһ 2825
126 Әбү Дауыд 2600
127 Тирмизи 3444
128 Бохари 2993

***105 – /Әгүҙү би кәлимәтилләһиттәммәти мин шәрри мә халәкъ/***

105 — «Аллаһ ﷻ халикъ кылган нәрсәләрнең явызлыгыннан, Аның камил сүзләренә[129] сыенам»[130]

## 80 – Берәр нәрсәгә шатланганда яки инде берәр нәрсә ошамаганда укыла торган дога

106 — Пәйгамбәребез ﷺ берәр нәрсәгә сөенсә болай дип әйтә иде:

«الْحَمْدُ لِلَّهِ الَّذِى بِنِعْمَتِهِ تَتِمُّ الصَّالِحَاتُ»

***– /Әлхәмдүлилләһил-ләҙи бинигьмәтиһи тәтиммүс-салихәт/***

— «Аллаһка барча мактау! Аның нигъмәте белән изелекләр эшләнә»

Ә инде пәйгамбәребезгә берәр нәрсә ошамаса, болай дип әйтә торган иде:

«الْحَمْدُ لِلَّهِ عَلَى كُلِّ حَالٍ»

***– /Әлхәмдүлилләһи галә күлли хәл/***

— «Нәрсә генә булса да, Аллаһка барча мактау!»[131]

## 81 – Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтүнең фазыйләте

107 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Миңа бер тапкыр салават кылучыга, Аллаһ аңа ун

---

129 Кәүния һәм шәрьгыя сүзләр кирә. Кәүния, мәсәлән Аллаһ бер нәрсәнең булуын теләсә, Ул аңа бул ди һәм була. Шәрьгыя, мәсәлән ул бәла-каза төшкәнче һәм төшкәннән соң мөмкин; аятел көрсине кич белән укыган кеше төне буе шәйтаннан саклана - бу бәла төшкәнче Аллаһның аяте белән саклану, чирләгән кеше фәтихә сүрәсе белән дәвалана - бу бәла төшкәннән соң Аның сүзе белән саклану

130 Мөслим 2708. Әгәр кеше нинди дә булса өйдә тукталса һәм ошбу доганы укыса, бу өйдән киткәнгә кадәр аңа бернәрсә дә зыян китермәс

131 Ибен Мәҗәһ 3803

тапкыр салават кыла»[132]

108 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Минем каберемне бәйрәм урыны итмәгез, ә миңа салават кылыгыз! Хакыйкатьтә, кайда гына булсагыз да сезнең салаватларыгыз миңа ирешә»[133]

109 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Саран шул кеше, аның янында мине искә алып та миңа салават кылмаучы»[134]

110 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Хакыйкатьтә, Аллаһның җирдә сәяхәт кылучы фәрештәләре бар, Алар өммәтемнең сәламнәрен миңа җиткерәләр»[135]

111 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Кем дә кем миңа сәлам әйтә икән, һичшиксез, аңа җавап бирер өчен, Аллаһ миңа җанымны кайтарачак»[136]

## 82 – Сәламләшү

«السَّلاَمُ عَلَيْكُمْ وَرَحْمَةُ اللَّهِ وَبَرَكَاتُهُ»

***– /Әссәләмү галәйкүм үә рахмәтуллаһи үә бәракәтүһ/***

— «Сезгә Аллаһның сәламе, рәхмәте һәм бәракәте булсын!»

112 — Гыймран бин Хусайн ؓ әйтте: «Бер кеше пәйгамбәребез ﷺ янына килде дә: «Әссәләмү галәйкүм!», — дип әйтте, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : «Ун», — диде. Аннан соң икенче кеше килде дә: «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһ!», — дип әйтте. Пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, аннан соң ул утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : «Егерме», — диде. Аннан соң өченче кеше килде һәм: «Әссәләмү галәйкүм вә рахмәтуллаһи

132 Мөслим 384
133 Әбү Дауыд 2042
134 Тирмизи 3546
135 Нәсәи 1282
136 Әбү Дауыд 2041

вә бәракәтүһ!», — дип әйтте, һәм пәйгамбәребез ﷺ аның сәламенә җавап бирде, шуннан соң теге утырды, ә пәйгамбәр ﷺ : «Утыз», — диде»[137]

113 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте: «Иман китермичә сез Җәннәткә керә алмассыз, ә инде бер-берегезне яратканга кадәр иманлы булмассыз. Сезгә бер-берегезне яратуга китерә торган нәрсәне әйтергәме? Бер-берегез белән ешрак сәламләшегез!»[138]

## 83 – Әтәч кычкырганда укыла торган дога

115 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә әтәч кычкырганын ишетсәгез, Аллаһтан шәфкатьлек сорагыз, чөнки, хакыйкатьтә, ул әтәч фәрештәне күрде. Әгәр ишәк тавышын ишетсәгез, шәйтаннан Аллаһка сыеныгыз, чөнки, хакыйкатьтә, ул ишәк шәйтанны күрде»[139]

## 84 – Төнлә эт өргәндә укыла торган дога

116 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә төнлә эт өргәнен яки ишәк кычкырганын ишетсәгез, алардан Аллаһка сыеныгыз, чөнки, хакыйкатьтә, алар сез күрмәгән нәрсәне күрәләр»[140]

## 85 – Синең тарафтан рәнҗетелгән кешегә карата укыла торган дога

١١٧ ـ «اللَّهُمَّ فَأَيُّمَا مُؤْمِنٍ سَبَبْتُهُ فَاجْعَلْ ذَلِكَ لَهُ قُرْبَةً إِلَيْكَ يَوْمَ الْقِيَامَةِ»

***117 – /Аллаһүммә фә‘әйүмә мү‘минин сәбәбтүһү фәҗгал ҙәликә ләһү куръбәтән иләйкә йәүмәл-кыйәмәһ/***

---

137 Әбү Дауыд 5195
138 Мөслим 54
139 Бохари 3303
140 Әбү Дауыд 5103

117 — «Әй Аллаһ! Мин берәр мөэминне рәнҗеткән булсам, бу рәнҗетүне аның өчен Кыямәт Көнендә Сиңа якынаю сәбәбе ит»[141]

## 86 – Бер мөселман икенче мөселманны мактаганда укыла торган дога

118 — Пәйгамбәребез ﷺ әйтте:

— «Әгәр дә берәрегезгә дустын мактарга туры килсә, болай дип әйтсен:

«أَحْسِبُ فُلاَنًا وَاللَّهُ حَسِيبُهُ وَلاَ أُزَكِّى عَلَى اللَّهِ أَحَدًا»

***– /Әхсибү фүләнән үәАллаһү хәсибүһү үә лә үзәкки галәллаһи әхәдә/***

— «Мин фәлән кешене мондый дип саныйм, Аллаһ аны Үзе хисап кылучы, ләкин мин Аллаһ каршында беркемне дә мактамыйм» чынлап та аны белә торган булса, мин аны шундый-шундый дип саныйм, дип әйтеп уза[142]

## 87 – Әгәр мөселманны мактасалар, макталган мөселман укый торган дога

١١٩ – «اللَّهُمَّ لاَ تُؤَاخِذْنِي بِمَا يَقُولُونَ، وَاغْفِرْ لِي مَا لاَ يَعْلَمُونَ، وَاجْعَلْنِي خَيْراً مِمَّا يَظُنُّونَ»

***119 – /Аллаһүммә лә түʻәхыйҙни бимә йәкулүн, үәгьфир ли мә лә йәгьләмүн, үәҗгални хайран миммә йәҙуннүн/***

119 — «Әй Аллаһ! Алар әйткән сүзләр өчен мине җәзалама, алар белмәгән нәрсәләремне миңа ярлыка һәм алар уйлаганнан мине яхшырак кыл»[143]

---

141 Бохари 6361

142 Бохари 2662

143 әл-Әдәб әл-Мүфрад 761

## 88 – Гаҗәпләнгәндә яки шатланганда әйтелә торган сүзләр

١٢٠ – «سُبْحَانَ اللَّهِ»

***120 – /СүбхәнәАллаһ/***

120 — «Аллаһ һәр кимчелектән пакь»

١٢١ – «اللَّهُ أَكْبَرُ»

***121 – /Аллаһү әкбәръ/***

121 — «Аллаһ бөек»

## 89 – Шатлык килгәндә нәрсә эшләргә

122 — «Әгәр дә пәйгамбәребезне ﷺ сөендерә торган хәл булса, ул Аллаһ тәбәракә вә тәгаләгә шөкер итеп сәҗдәгә китә иде»[144]

## 90 – Тәнендә авырту сизгән кеше укый торган дога

123 — Кулыңны тәнеңнең авырткан урынына куй да, өч тапкыр:

«بِسْمِ اللَّهِ»

***– /Бисмилләһ/***

— «Аллаһ исеме белән», — дип әйт, аннары 7 тапкыр:

«أَعُوذُ بِاللَّهِ وَقُدْرَتِهِ مِنْ شَرِّ مَا أَجِدُ وَأُحَاذِرُ»

***– /Әгүҙү билләһи үә кудратиһи мин шәрри мә әҗиду үә үхәҙиру/***

— «Мин сизгән һәм курыккан яманлыклардан Аллаһка вә Аның кодрәтенә сыенам»[145] — диген.

144 Ибен Мәҗәһ 1394

145 Мөслим 2202

## 91 – Үз күзең тиюдән курыкканда бәракәт сорап дога кылырга тиешле

124 — «Әгәр берәрегез үзендә яки малында яки кардәшендә аны гаҗәпләндерерлек нәрсә күрсә, аңа бәракәт иңүен сорасын, чөнки күз тию – хак (дөрес)»[146]

## 92 – Курыкканда әйтелә торган сүз

١٢٥ – «لاَ إِلَهَ إِلاَّ اللَّهُ»

***125 – /Лә иләһә иллә Аллаһ/***

125 — «Аллаһтан башка иләһ юк»[147]

## 93 – Мал суйганда нәрсә әйтелә

١٢٦ – «بِسْمِ اللَّهِ وَاللَّهُ أَكْبَرُ»

***126 – /Бисмилләһи үәАллаһү әкбәръ/***

126 — «Аллаһ исеме белән һәм Аллаһ бөек»[148]

146 Сахих әл-Җәмигъ әс-Сагыйрь 556
147 Бохари 3346
148 Бохари 5558

## ЭЧТӘЛЕК

Зикернең фазыйләте....................................................3
Дога кылуның әдәпләре..............................................6
Дога кабул була торган вакытлар һәм урыннар...........7
1 – Йокыдан уянгач та укыла торган зикер-догалар...8
2 – Кием кигәндә укыла торган дога...........................10
3 – Яңа кием кигәндә укыла торган дога....................10
4 – Яңа кием киючегә укыла торган дога...................10
5 – Кием салгач әйтелә.................................................11
6 – Бәдрәфкә кергәндә укыла торган дога..................11
7 – Бәдрәфтән чыккач укыла торган дога..................11
8 – Таһәрат алдыннан әйтелә........................................11
9 – Таһәрат алганнан соң әйтелә торган дога............12
10 – Өйдән чыкканда укыла торган дога...................13
11 – Өйгә кергәндә укыла торган дога........................14
12 – Мәчеткә барганда укыла торган дога.................14
13 – Мәчеткә кергәндә укыла торган дога.................14
14 – Мәчеттән чыкканда укыла торган дога..............15
15 – Азан әйткәндә укыла торган зикер-догалар.......15
16 – Истихара (хәерлене сорау) намазының догасы..16
17 – Иртә һәм кич укыла торган догалар...................18
18 – Йоклар алдыннан укыла торган догалар............21
19 – Төнлә йоклый алмыйча боргаланып ятканда укыла торган дога.........................................................22
20 – Йоклаганда төшендә куркучы һәм борчылучы укый торган дога...........................................................22
21 – Начар төш күргәндә нәрсә эшләргә....................23
22 – Витр намазындагы кунүт догасы........................23
23 – Тынычсызлык һәм ямансу биләп алганда укыла торган дога.....................................................................24
24 – Олы кайгы килгәндә укыла торган дога............25
25 – Дошман яки гаделсез хөкемдарлар белән очрашудан курыкканда укыла торган дога...................26
26 – Дошманга каршы укыла торган дога...................26
27 – Берәрсеннән курыкканда укыла торган дога...26

28 – Бурычларны түләү өчен ярдәм сорап укыла торган дога..........................................................27
29 – Кешегә берәр эш авыр күренгәндә укыла торган дога..........................................................27
30 – Гөнаһ кылган кеше нәрсә эшләргә һәм укырга тиеш..........................................................28
31 – Кешегә берәр нәрсә ошамаганда яки бернәрсә дә эшли алмаган очракта укыла торган дога....................28
32 – Баласы туган кешегә котлап әйтелә торган дога һәм аңа җавап..........................................................28
33 – Балаларны саклау өчен укыла торган дога.......29
34 – Авыруны зиярат кылганда укыла торган дога.30
35 – Авыруны зиярат кылуның фазыйләте...............30
36 – Яшәү өметен югалткан авыруның догасы.........30
37 – Үлүчегә тәлкыйнь кылу..........................................31
38 – Кайгыга юлыккан кеше укый торган дога........31
39 – Үлгән кешенең күзләрен йомдыргач укыла торган дога..........................................................31
40 – Җеназа намазы догасы..........................................32
41 – Сабыйның җеназасында укыла торган дога.....33
42 – Тәгъзия догасы.........................................................33
43 – Мәетне кабергә куйганда укыла торган дога...33
44 – Мәетне җирләгәч укыла торган дога.................34
45 – Мәетне җирләгәч укыла торган дога.................34
46 – Җил чыкканда укыла торган дога......................34
47 – Күк күкрәгәндә укыла торган дога.....................35
48 – Яңгыр сораганда укыла торган дога..................35
49 – Яңгыр яуганда укыла торган дога......................35
50 – Яңгыр яуганнән соң укыла торган дога............35
51 – Берөзлексез яуган яңгырны туктатуны сорап укыла торган дога..........................................................36
52 – Яңа туган ай күргәндә укыла торган дога.........36
53 – Авыз ачканда укый торган дога..........................36
54 – Ашар алдыннан укый торган дога......................37
55 – Ашаганнан соң укыла торган дога.....................37
56 – Мәҗлес хуҗасы өчен укыла торган дога...........37

57 – Беренче өлгергән җимешләрне күргәч укыла торган дога.....38
58 – Төчкергәннән соң укыла торган дога.....38
59 – Яңа өйләнгәннәрне котлап укыла торган дога.38
60 – Өйләнгән кеше укый торган дога.....39
61 – Хатын белән җенси якынлык кылыр алдыннан укый торган дога.....39
62 – Ачуланганда укыла торган дога.....39
63 – Бәла-казага ирешүчене күргәндә укыла торган дога.....40
64 – Нинди дә булса җыенда яки мәҗлестә укыла торган дога.....40
65 – Җыен-мәҗлес ахырында укыла торган дога....40
66 – Сиңа яхшылык эшләгән кешегә әйтелә торган до га.....41
67 – Сиңа үзенең акча-байлыгын тәкъдим итүче кешегә укыла торган дога.....41
68 – Бурычны кайтарганда укыла торган дога.....41
69 – Ширектән курыкканда укыла торган дога.....42
70 – Әгәр дә берәү сиңа: «Аллаһ сиңа бәрәкәт бирсен!» /БәракәАллаһү фикә/ – дисә, ничек җавап бирелә.....42
71 – Машинага, хайванга яки нәрсәгә булса да утырганда укыла торган дога.....42
72 – Сәфәр догасы.....43
73 – Шәһәр-авылга кергәндә укыла торган дога.....44
74 – Базарга кергәндә укыла торган дога.....45
75 – Менге ат кебек атланып йөри торган хайван абынса укыла торган дога.....45
76 – Мөсафирның мөкыймга укый торган догасы....45
77 – Мөкыймның мөсафирга укый торган догасы....46
78 – Сәфәрдә тәкбир һәм тәсбих.....46
79 – Сәфәрдә чакта яки башка вакытта берәр өйдә тукталганда укыла торган дога.....46
80 – Берәр нәрсәгә шатланганда яки инде берәр нәрсә ошамаганда укыла торган дога.....47
81 – Пәйгамбәргә ﷺ салават әйтүнең фазыйләте......47

82 – Сәламләшү.......................................................................48
83 – Әтәч кычкырганда укыла торган дога...............49
84 – Төнлә эт өргәндә укыла торган дога..................49
85 – Синең тарафтан рәнҗетелгән кешегә карата укыла торган дога...............................................................49
86 – Бер мөселман икенче мөселманны мактаганда укыла торган дога...........................................................50
87 – Әгәр мөселманны мактасалар, макталган мөселман укый торган дога..............................................................50
88 – Гаҗәпләнгәндә яки шатланганда әйтелә торган сүзләр....................................................................................51
89 – Шатлык килгәндә нәрсә эшләргә........................51
90 – Авырту сизгән кеше укый торган дога...............51
91 – Үз күзең тиюдән курыкканда бәракәт сорап дога кылырга тиешле..........................................................52
92 – Курыкканда әйтелә торган сүз............................52
93 – Мал суйганда нәрсә әйтелә..................................52